# Самарские татары
# Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 1 (46), ЯНВАРЬ–МАРТ 2025

ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА




РОЖДЕННАЯ В ЗОЛОТОЕ ВРЕМЯ



САБЫЙЛАРДАН
ҖӘННӘТ ИСЕ КИЛӘ



ИСТОРИЯ КИПЧАКОВ ГЛУБОКА, РОМАНТИЧНА И ЗАГАДОЧНА



“ҺӘР САМИМИ КҮЗЛӘРДӘ ШӘХЕС КҮРДЕМ МИН!”



## ЖИЛ МУЗЫКОЙ
## И ДЕЛИЛСЯ ЕЮ С ЛЮДЬМИ

6+

# ВАША РЕКЛАМА
# В ТАТАРСКИХ СМИ РЕГИОНА

По вопросам размещения обращаться по телефону 8-917-104-44-45












# Хөрмәтле дуслар!

Сезнең игътибарыгызга журналыбызның язгы санын тәкъдим итәбез.

Аны бераз тоткарланып чыгарган өчен сездән гафу үтенәбез. Эш шунда ки, 25 мартта узган өлкә ифтары турындагы мәкаләне җәйге санга калдыру дөрес булмас иде. Шуңа күрә әлеге язманы кертеп, журналны соңрак бастырырга булдык.

Икенчедән, “Самар татарлары”н әзерләү белән беррәттән “Россия татарлары” дип исемләнгән федераль басма өстендә эшләдек. Безнең журнал турында башка регионнарда һаман да күбрәк белә башладылар. Еллар узу белән мәкаләләребезнең географиясе дә киңәя барды. Шул рәвешле бездә федераль проект булдыру идеясе туды. “Россия татарлары” журналында башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тормышын, эшчәнлеген яктыртучы мәкаләләр дә урын алачак.

Федераль санныбызны шулай ук язын чыгарырга ниятлибез. Теләгән кешеләр, редакциябезгә мөрәҗәгать итеп яисә tatmagazine.ru сайтына кереп, “Россия татарлары”ның беренче саны белән таныша алалар. Шуны да исегезгә төшерәбез: әлеге сайтта журналыбызның барлык саннарының электрон версияләрен укырга мөмкин.

Безнең язмаларны ләззәтләнеп укырсыз һәм samartatarlary@bk.ru адресы буенча электрон почтага үз фикерләрегезне, тәкъдимнәрегезне җибәрерсез дип ышанып калабыз.



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналының баш мөхәррире*

# Уважаемые друзья!

Представляем вашему вниманию первый в этом году, весенний номер нашего журнала.

Его выпуск немного подзадержался, за что приносим свои самые искренние извинения. Дело в том, что было бы неправильно переносить на летний номер материал об областном ифтаре, который состоялся 25 марта, в то время, когда журнал должен уже печататься в типографии. Поэтому нами было принято решение выпустить его позже. Во-вторых, параллельно с самарским изданием наша команда работала над созданием пробного, или как его еще называют, пилотного номера федерального издания «Татары России». О нашем журнале всё больше стали узнавать в других регионах, куда он отправляется почтой. Стала расширяться и география наших статей и информационных материалов. Так родилась идея о создании федерального проекта, целью которого станет информирование о том, как и какую работу по сохранению татарской идентичности наши соплеменники ведут за пределами Самарской области. Выход пилотного выпуска федерального номера мы также запланировали на весну, чтобы как можно скорее понять, насколько будет востребована такая информация, найдет ли она своего читателя. Все желающие смогут с ознакомиться с пробной версией этого издания, обратившись в нашу редакцию или на сайте Tatmagazine.ru, где мы размещаем оцифрованные версии наших журналов и книг.

Желаю вам всем приятного прочтения и рассчитываем на ваши предложения и отклики, которые вы можете присылать на нашу почту samartatarlary@bk.ru


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович** – президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович** – председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович** – гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна** – главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович** – старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович** – председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна** – директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович** – член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширязданов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:


Суд принял решение по памятнику хану Котрагу в Ширяево..6
Областной ифтар собрал около 1000 гостей.....7
Рафаэль Баһаутдинов: “Районыбыз белән горурланырлык” булсын!”.....9
Рожденная в золотое время.....12
Утыз ел динебезгә һәм халкыбызга хезмәттә.....15
“Балалар татар телен яратып үзләштерәләр икән, бу - минем өчен олы бәхет”.....16
“Һәр самими күзләрдә шәхес күрдем мин”.....19
Сабыйлардан Җәннәт исе килә.....21
Бәхет өчен күп кирәкме?!.....24
Нәселләре белән уңганнар!.....27
Гефеста-кузнеца понять пытался.....31
Такими семьями и сильна Россия.....42
“Сугыш еллары - төзәлмәс йөрәк яраларым”.....50
Чиксез авырлыклар кичерсәләр дә, “сугыш балалары” матур яшәделәр.....53
История кипчаков глубока, романтична и загадочна.....57
Разбойники, бандиты и неблагородные пираты.....60
Китап - ул бер буынның икенче буынга рухи васыяте.....62
Традиции далеких мест и наш край.....66
Есть такие роды и племена... .....68
Жил музыкой и делился ею с людьми.....69
Трудно всем: и подросткам, и родителям.....79
Житмеш төрле һөнәр иясе.....83





24 БӘХЕТ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМЕ?!





42 ТАКИМИ СЕМЬЯМИ И СИЛЬНА РОССИЯ





62 КИТАП - УЛ БЕР БУЫННЫҢ ИКЕНЧЕ БУЫНГА РУХИ ВАСЫЯТЕ





79 ТРУДНО ВСЕМ: И ПОДРОСТКАМ, И РОДИТЕЛЯМ


## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2023 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**


Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 1 (46), январь–март, 2025
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 15 апреля 2025 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная

## ГЛАВА ГОСУДАРСТВА ВСТРЕТИЛСЯ С ВЕРХОВНЫМ МУФТИЕМ

*kp.ru*



Президент России Владимир Путин встретился с верховным муфтием, председателем Центрального духовного управления мусульман России Талгатом Таджуддином. Глава государства поблагодарил муфтия и всех представителей ислама за вклад в укрепление межконфессионального единства и согласия в стране.

Путин подчеркнул, что мусульмане являются неотъемлемой частью российского общества. Он отметил, что представители ислама вносят значительный вклад в единство и силу России, что помогает преодолевать сложности и угрозы, обеспечивая развитие страны.

Президент также напомнил о мужестве бойцов-мусульман, участвующих в специальной военной операции на Украине. Исповедующие ислам россияне вносят огромный вклад в развитие страны, верой и правдой служат Отчизне, подчеркнул Путин.

По данным Духовного управления мусульман России, ислам в стране исповедуют около 20 миллионов человек. С 1991 года количество мечетей в России увеличилось в 60 раз, а 25 тысяч россиян ежегодно совершают хадж.



## БЕЗНЕҢ ГЕРОЙ

Сызран шәһәрендә туып-үскән милләттәшебез Азиз Мәхсүт улы Кудряковка Россия Федерациясе Герое исеме бирелгән. Якташыбыз махсус операциягә беренче көненнән киткән. 2024 елның мартында хәрби казанышлары өчен РФ Герое исеменә тәкъдим ителгән. Кызганычка, исән чагында "Алтын йолдыз"ын алып өлгермәгән - 25 июльдә һәлак булган. Февраль башында Президент Указы буенча Россия Герое исеменә лаек булган. Хөкүмәт бүләге күп балалы әти-әнисенә - Әлфия Харис кызына һәм Виталий Владимир улы Сухановларга тапшырылган. Аларның ике улы махсус хәрби операциядә хезмәт иткән.

## В КАЗАНИ ПРОШЕЛ XIII ВСЕРОССИЙСКИЙ СХОД ПРЕДПРИНИМАТЕЛЕЙ ТАТАРСКИХ СЁЛ

*apkrb.info*

С 26 по 28 февраля 2025 года Всемирный конгресс татар проводил XIII Всероссийский сход предпринимателей из татарских сёл регионов Российской Федерации. Сход собрал более 900 участников из 48 регионов России. Делегацию Бураевского района Республики Башкортостан представили главный зоотехник УСХ Ленар Багауов, ИП глава К(Ф)Х Рамиль Зарипов и ИП глава К(Ф)Х Булат Габдуллин. Среди гостей и участников – представители малого бизнеса, фермерских хозяйств, подворий и органов государственной власти. Мероприятие стало важной площадкой для обмена опытом и обсуждения вопросов развития сельских территорий.

Мероприятие началось с торжественного открытия в Академии наук Республики Татарстан, после чего начались работы дискуссионных площадок.

27 февраля участники форума посетили в Тетюшский и Апастовский муниципальные районы Татарстана, где ознакомились с опытом комплексного развития татарских сел. Экскурсионные мероприятия посвящены достижениям в агропромышленном комплексе, внедрению инновационных технологий и развитию инфраструктуры.

Завершающий день Схода прошел в ГТРК «Корстон». Участники посетили выставку-ярмарку продукции и товаров народных промыслов, а также приняли участие в пленарном заседании с участием Раиса Республики Татарстан Р. Н. Минихановым.



## ГУБЕРНАТОР ВЯЧЕСЛАВ ФЕДОРИЩЕВ ПЕРЕДАЛ СПЕЦТЕХНИКУ И ОБОРУДОВАНИЕ ДЛЯ САМАРСКИХ БОЙЦОВ

*Samregion.ru*

Партия была сформирована по заявкам командиров воинских частей исходя из потребностей на передовой и уже отправлена в зону проведения специальной военной операции.

Более 300 квадрокоптеров, 3 специализированных автомобиля «Урал», 190 отопительных печей, 50 маскировочных сетей. Техника и имущество будут распределены для 15-й и 30-й мотострелковых бригад 2-й гвардейской общевойсковой Краснознаменной армии, 88 отдельной мотострелковой бригады, 3-й отдельной бригады спецназа, 1445-го мотострелкового полка.

## САМАРСКИЕ ПРЕДПРИЯТИЯ ПОСЕТИЛА ДЕЛЕГАЦИЯ РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН

В рамках укрепления торгово-экономических связей двух регионов представители бизнес-миссии посетили крупнейшие предприятия региона, в том числе филиал ПАО «Россети Волга» – «Самарские распределительные сети», ПАО «ОДК-Кузнецов», АО «Самарская кабельная компания».

Самарские энергетики и гости обсудили перспективы дальнейшего сотрудничества. На территории Республики Башкортостан расположены крупные производители кабельной продукции, коммутационного и силового оборудования. Часть предприятий имеет аттестацию оборудования в ПАО «Россети», что позволяет поставщикам участвовать в закупочных процедурах и поставлять оборудование на строящиеся и реконструируемые объекты.

Самарская область и Республика Башкортостан являются одними из лидирующих регионов по объемам промышленного производства в Приволжском федеральном округе. Такие результаты стали возможны в том числе благодаря тесному сотрудничеству и развитой системе промышленной кооперации.

## ДВА НОВЫХ ДЕПУТАТА ГАБДРАХМАНОВ И ЗАХАРКИН ВОШЛИ В СОСТАВ ДУМЫ САМАРЫ

***В Самарской городской думе пополнился состав депутатов. Туда включили еще двух парламентариев.***

***kp.ru***



– Одним из них стал Марат Габдрахманов. Раньше он возглавлял различные муниципальные предприятия, занимал должность замглавы Самарского района по вопросам потребительского рынка, товарам и услугам, – рассказали в гордуме о новом депутате.

С 2013 года и по настоящее время Марат Габдрахманов занимает пост вице-президента корпорации «РосРегион Развитие», где курирует инвестиционные проекты, крупные региональные проекты в сфере жилищного строительства, управления коммерческой недвижимостью и ритейла.

В 2020 году Марата Габдрахманова избрали в совет депутатов Самарского района. В этом году его делегировали в гордуму 7-го созыва.

## КРУПНАЯ ПАРТИЯ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНОЙ ГУМАНИТАРНОЙ ПОМОЩИ ОТПРАВИЛАСЬ ИЗ СЫЗРАНИ В КУРСКУЮ ОБЛАСТЬ

***7 марта несколько тонн гуманитарного груза были отправлены для жителей Курской области.***

Активное участие в организации сбора гуманитарной помощи приняли городские национальные общественные организации: Сызранский филиал Самарской региональной армянской национально-культурной автономии «Наири», национально-культурная автономия татар г. о. Сызрань, а также представители цыган Сызрани, местные волонтеры, предприниматели и специалисты Сызранского дома молодежи.

В результате совместных усилий удалось собрать около двух тонн гуманитарного груза. Это преимущественно вещи для жителей Курской области – как для взрослых, так и для детей. В Доме молодежи осуществлялся прием и сортировка груза партиями по 20 кг, далее следовали погрузочные работы и отправка силами «Почты России».

## О ТРАДИЦИЯХ И КУЛЬТУРЕ ТАТАР В НИЖЕГОРОДСКОЙ ОБЛАСТИ РАССКАЖЕТ НОВЫЙ ТЕЛЕВИЗИОННЫЙ ПРОЕКТ ГТРК «НИЖНИЙ НОВГОРОД»

***tatar-congress.org***

Татары – вторая по численности нация в Нижегородской области. «Нижгары» – так по-русски называют местных татар, об их жизни и культуре новый телевизионный проект ГТРК «Нижний Новгород».

Проект приурочен к 20-летию Региональной национально-культурной автономии татар Нижегородской области.

Выход телепередачи запланирован с периодичностью 2 раза в месяц (с повторами в течении дня) на трех телеканалах, вещающих на Нижегородскую область и близлежащие регионы, а также на всех интернет-ресурсах и соцсетях ВГТРК «Нижний Новгород».

Проект реализуется при поддержке гранта Раиса Республики Татарстан на развитие гражданского общества.



## СӘХНӘДӘ - ТАРИХ ДӘРЕСЕ

23 февраль көнне «Чайка» Мәдәният йортында «Ялкынлы яшьлек» татар халык җыр, бию һәм шигърият ансамбле Ватанны саклаучылар көненә концерт куйды. Чара төрле тарихи чорларда Ватанны саклаучы батырларга хөрмәт символы булып яңгырады. Сәхнәдән патриотик җырлар яңгырады, театраль күренешләр тәкъдим ителде. Чарага гаиләләре белән бергә чакырылган махсус хәрби операция хәрбиләренә аерым игътибар бирелде, истәлекле бүләкләр тапшырылды. Кичә патриотик җырлар белән тәмамланды. Зал таныш көйләрне артистларга кушылып көйләде, ә күпләрнең күзләрендә яшь бөртекләре ялтырады.

# О ВЕЛИКИХ ЖЕНЩИНАХ ТАТАРСКОГО НАРОДА

*samtatnews.ru*

В школе «Яктылык», по инициативе советника директора по воспитанию А.А. Мамышевой, для учащихся 5-х классов была организована классная встреча «Великие женщины».

Приглашенный спикер Дильфуза Рустямовна Асанова – основатель АНО «Центр помощи семье «Единение», юрист, медиатор, член ОП ЕАЭС, член расширенного состава молодежного правительства Самарской области 7-го созыва, член Национальной ассоциации юристов России, член Международной ассоциации психологов. Лауреат XXVI Самарской областной общественной акции «Благородство» в номинации «Волонтеры», которая проводится Самарским областным отделением Союза журналистов России и Ассоциацией творческих союзов Самарской области при официальной поддержке министерства культуры Самарской области.

Встреча прошла в неформальной обстановке. Дильфуза Рустямовна рассказала о великих женщинах татарского народа и о их значимом вкладе в культуру и науку.





# БОЛЬШЕ ТЫСЯЧИ БОЙЦОВ СВО ПОДАЛИ ЗАЯВКИ НА УЧАСТИЕ В ПРОЕКТЕ «БАТЫРЛАР. ГЕРОИ ТАТАРСТАНА»

*tatar-inform.ru*

Заявку на участие в проекте «Батырлар. Герои Татарстана» подал 1061 участник спецоперации.

Успешно прошедших отбор кандидатов ждет обучение по специальной образовательной программе профессиональной переподготовки в Высшей школе государственного и муниципального управления Казанского (Приволжского) федерального университета.

В проекте могут принять участие как ветераны, так и участники СВО. Заявки принимаются до 30 марта.

«Татар-информ» рассказывал, что в Татарстане запустили проект «Батырлар. Герои Татарстана». Это аналог программы «Время героев», которая направлена на переобучение участников СВО. Получив новые знания и практику, военнослужащие смогут стать перспективными руководителями для замещения должностей в системе государственного и муниципального управления и в иных сферах жизни в Татарстане.



# КАМИЛУ ВАЛИЕВУ ОСТАВИЛИ В ПУЛЕ МЕЖДУНАРОДНОГО ДОПИНГ-ТЕСТИРОВАНИЯ ISU

*realnoevremya.ru*

Фигуристка Камила Валиева остается в пуле международного допинг-тестирования. Информацию опубликовал ТАСС со ссылкой на документы Международного союза конькобежцев (ISU).

Всего в пуле допинг-тестирования ISU остаются семь российских фигуристов: Александр Галлямов, Анастасия Мишина, Аделия Петросян, Евгений Семененко, Иван Букин, Александра Степанова и Камила Валиева. Представленные спортсмены обязаны оперативно вносить информацию в систему контроля ADAMS.

При этом Камила Валиева дисквалифицирована за нарушение антидопинговых правил до декабря 2025 года. Фигуристку лишили практически всех завоеванных титулов из-за обнаруженного в допинг-пробе запрещенного триметазидина.

В начале марта стало известно, что Валиева намерена возобновить тренировки после окончания дисквалификации.

# Суд принял решение по памятнику хану Котрагу в Ширяево

***Памятник булгарскому хану Котрагу в селе Ширяево должен быть снесен. Такое решение принял Арбитражный суд Самарской области. Текст решения при этом пока не опубликован.***

*Подготовлено на основе материала volga.news*

Напомним, в январе 2023 г. памятник был установлен на Поповой горе на исторической площадке, которую с 2008 г. развивает Культурно-исторический фонд «Булгарское наследие». Рядом находится еще одна символическая фигура - памятный знак «Южная граница Волжской Булгарии».

Согласно легенде, в VII веке хан Котраг привел часть булгарских племен с Северного Кавказа на Среднюю Волгу и основал здесь государство Волжская Булгария.

Над монументом работал болгарский скульптор Дишко Дишков, который ранее создал памятник хану Алцеку, установленный в итальянском городе Челе де Булгаре, а также хану Аспаруху - в Болгарии.

В ноябре 2024 года на сайте администрации Жигулевска, в чьи административные границы входит Ширяево, появилось постановление о демонтаже скульптурной композиции в срок до 6 декабря 2024 года. В качестве основания своих требований администрация указала нарушение «процедуры по предварительному получению разрешения на установку».

При этом в начале ноября 2024 года администрация Жигулевска провела опрос местных жителей по вопросу демонтажа скульптурной композиции. 459 человек выступили за демонтаж памятника, 160 - против.

КИФ «Булгарское наследие» обратился в арбитражный суд с иском об отмене решения о демонтаже. В свою очередь, администрация города вышла с встречным иском, в котором требовала снести монумент в течение месяца со дня вступления решения суда в законную силу. В итоге суд встал на сторону администрации, полностью отказав в удовлетворении иска фонда.

Насколько можно судить из публикаций в СМИ, против памятника выступили отдельные самарские краеведы и, что самое позорное, отдельные представители татарской общины. Так, звучали мнения, что за памятником Котрагу может стоять «посыл о великоболгарском национализме». Говорилось, в частности, о том, что установку памятника продвигало «болгаристское сообщество», которое придерживается теории происхождения современных татар от булгар без учета золотоордынского периода.

Выступавшие за демонтаж памятника также апеллировали к тому, что Болгария является членом НАТО и недружественной страной. При этом действительно в 2023-2024 гг. шло обсуждение демонтажа памятника советскому солдату-освободителю (народное название «Алеша»), в болгарском городе Пловдив.

Их оппоненты указывают, что памятник символизирует единые корни различных народов и содействует развитию культурно-исторического туризма, а также акцентируют доброе отношение простых болгар к России.





# ОБЛАСТНОЙ ИФТАР СОБРАЛ ОКОЛО 1000 ГОСТЕЙ

***23 марта на стадионе «Самара Солидарность Арена» прошел масштабный ифтар-меджлис. Яркое и наполненное глубоким смыслом мероприятие проводится в нашем многонациональном регионе вот уже второй год, символизируя единение народов, говорящих на разных языках и скрепленных единой мусульманской верой.***







Ифтар организован по инициативе Регионального духовного управления мусульман Самарской области при поддержке регионального правительства и национально-культурных объединений. В отличие от прошлогоднего мероприятия, собравшего около полутора тысяч человек, в этом году количество гостей было меньше, что обусловлено, в первую очередь, вопросами безопасности и, во-вторую, созданием более удобных условий самим гостям. Хочется отметить, что в этом году содержание и организация ифтара были более четкими и лаконичными. Аккуратно расставленные и сервированные столы аппетитно притягивали внимание, на светодиодных экранах транслировалось всё происходящее на сцене, а чуть позже здесь же можно было увидеть познавательные фильмы об истории волжских булгар и о значимости поста для правоверных мусульман. Достаточно четко были разделены женская и мужская половины зала, места для совершения коллективного намаза также вполне хватило всем. Порадовало, что разделить радость разговения с самарскими мусульманами приехали и многочисленные почетные гости. Среди











них Верховный муфтий России, председатель Центрального Духовного управления мусульман России Талгат хазрат Таджуддин, первый вице-губернатор Самарской области Александр Фетисов, заместитель премьер-министра Республики Татарстан, председатель Национального совета Всемирного конгресса татар Василь Шайхразиев, муфтий Татарстана Камиль Самигуллин.

Для участников мероприятия была подготовлена большая программа, которая включала в себя конкурсы и викторины на знание исламской культуры и традиций, выступления исполнителей исполнением мунаджатов (религиозных песнопений) из Казани и Самары. Особенностью текущего ифтара стал розыгрыш двух путевок в хадж от одного из спонсоров – производителя халяльной мясной продукции «Дуслык».

Выступая с приветственной речью, муфтий Талип хазрат Яруллин отметил важность сохранения традиционных духовных ценностей и напомнил собравшимся, что самарский областной ифтар проходит в очень важное и непростое для нашей страны время. 2025 год решением Президента страны назван Годом защитника Отечества в память о тех, кто добывал победу в Великой Отечественной войне и тех, кто приближает ее сегодня в ходе специальной военной операции.

– Сегодня представители разных народов собрались здесь, чтобы совершить разговение и вместе порадоваться. Я благодарю всех тех, кто принимал участие в проведении этого праздника и гостей. Радует, что в наших мусульманских семьях основы традиционного ислама передаются от взрослых детям, что наши семьи многодетные и что воспитание в них основывается на уважении своей духовной культуры, сохранении национальных традиций и любви к своей стране. Сегодня наши братья вместе с представителями других народов и вероисповеданий отстаивают интересы нашей страны в зоне проведения СВО. Хочу сказать огромное спасибо им и их родителям, которые сумели привить им чувство ответственности за судьбу своей страны, – отметил Талип Яруллин.

Поприветствовал собравшихся и муфтий Татарстана Камиль хазрат Самигуллин. Он передал сердечный салям от всех мусульман Татарстана, подчеркнув, что месяц Рамадан собрал людей из разных уголков Самарской области для совместных молитв перед Всевышним, поделился своими наставлениями о достоинствах и значении месяца Рамадан, подчеркнул важность поклонения в этот священный месяц.

Председатель Национального совета Всемирного конгресса татар Василь Шайхразиев также поздравил гостей областного ифтара с наступлением священного месяца Рамадан, пожелав всем мира, духовного обновления и созидания. Он поблагодарил правительство Самарской области и лично губернатора региона за всестороннюю поддержку в организации ифтара, отметив, что такие инициативы укрепляют межрегиональные связи и традиции взаимопомощи.

Слова благодарности от всех выступающих в этот вечер вполне заслуженно звучали в адрес спонсоров и многочисленной армии волонтеров, без участия которых проведение столь большого мероприятия было бы сложно представить.

# Рафаэль Баһаутдинов: “Районыбыз белән горурланырлык” булсын!”

**20 мартта өлкәбездәге бердәнбер татар районының башлыгы Рафаэль Камил улы Баһаутдиновка 60 яшь тулды**



Рафаэль Камил улы Татарстанның Чирмешән районы Светлогорск поселогында күп балалы гаиләдә туып-үсә. Мәктәп елларында малай активлыгы һәм яхшы укуы белән аерылып тора. Оештырылган барлык эшләрдә дә актив катнаша, башлап йөрүчеләрдән булачагы балачагыннан ук күренеп тора. Хәер, моны начар сыйфат дип санарга ярамый. Институтта укыганда да бар нәрсәгә дә өлгерә, комсомол тормышы үзәгендә дә кайный, әти-әнисеннән акча көтеп ятмый, үз көнен үзе күрергә тырышып, төрле эшләрдә эшли, әти-әнисе карамагында тагын дүрт бала булуын беркайчан да онытмый.

1987 елда Куйбышев авыл хуҗалыгы институтының агрономия бүлеген тәмамлагач, Рафаэль Баһаутдинов юллама буенча Тверь өлкәсенә эшкә китә һәм шунда өч ел буе баш агроном булып эшли. 1990 елда туган якларына кайткан яшь белгечне Челно-Вершины районының “Красный строитель” племзаводы бүлеге белән идарә итәргә куялар. Дүрт ел эшләгәннән соң Рафаэль Камил улы гаиләсе белән Похвистнево районының Стюхино авылына күчеп китә һәм “Мир” колхозы агрономы вазифаларына керешә.

Күп тә үтми, тәҗрибәле белгечне “Заря” колхозы рәисе итеп сайлыйлар. Яңа колхоз рәисе анда да сынатмый, икътисади яктан катлаулы булган 90нчы елларда колхозны саклап кала һәм хәтта позицияләрен ныгытуга ирешә.



Җитәкче 2003 елда Федераль “Идарәче кадрлар әзерләү программасы” буенча Самар дәүләт икътисади университетын тәмамлый, “Бердәм Россия” партиясенә керә. Укуын бик яхшы билгеләргә тәмамлаган Бәһаутдиновны Италиягә стажировкага җибәрәләр. Моның белән генә чикләнми героебыз, «Бизнес-планирование производства сельскохозяйственной продукции на основе современных технологий» курсларын да тәмамлый.

11 ел буе Рафаэль Камилович Солтангол авылы крестьян хуҗалыгын җитәкли. Авыл халкы белән берлектә яхшы уңышларга ирешәләр: эш тәртибе җайлана, хуҗалык аякларында нык басып тора. “Колхозны саклап кала алган кешегә берни дә куркыныч түгел”, - дип озаталар Бәһаутдиновны авылдашлары аңа Камышлы районы җитәкчесе булырга тәкъдим ителгәч.

Бу хәл 2009 ел язында була. “Бердәм Россия” партиясе аңа Камышлы районы җитәкчесе сайлауларына үз кандидатурасын куярга тәкъдим иткәч, колхоз рәисе уйлана, әлбәттә. “Ә ник район тормышын яхшыртуга алынмаска? Авыл хуҗалыгы юнәлешләрендә тәҗрибәм, белемем байтак, энергиям ташып тора. Гомерем буе туплаган тәҗрибәмне кулланып, Камышлы районына да файда китерә алырмын, дип ышанам” , - дигән фикергә килә Рафаэль Камилович. һәм әти-әнисенең, мәчет әһелләренең хәер-фатихаларын алып, сайлауларда катнашырга карар кыла. Иң мөһиме – Камышлы районы халкы да аңа теләктәшлек белдерә. Шулай итеп, Рафаэль Бәһаутдинов Камышлы районы башлыгы итеп сайлана.

Җитәкче эшне районның көчле якларын үстерүгә, ә көчсез якларын ныгытуга юнәлдерә. Беренче чиратта, җирләрне авыл хуҗалыгы әйләнешенә кайтару, нәтиҗәле фермер хуҗалыкларына һәм колхозларга ярдәм итү, намуслы эшкуарларга, районга инвестицияләр җәлеп итүчеләргә гарантияләр булдыру, яшьләрне җирдә калдыру, тотрыксыз чорда дәүләт ярдәменә аерым игътибар бирү бурычларын район җитәкчелеге каршына куя.

Актив тормыш позициясендә торган бу кеше авыл халкының тормыш сыйфатын үзгәртә ала бит тәки. Моңа бәхәссез мисал итеп фактлар китерергә була. Беренче чиратта, район энергетиклар алдындагы бурычларын түли, торак фондына һәм социаль объектларга хезмәт күрсәтүче компанияләрнең акчаларын катгый контрольдә тота башлый. Яңа Усман авылында стоматология кабинеты ачыла, авылларда ФАПлар ремонтлана, авыл урамнары төзекләндерелә - район үзәгендә парк яңара, авылларда мәктәп, клуб тирәләре яшелләндерелә, чәчәкләр утыртыла, муниципаль бюджет чыгымнарын җитди контрольдә тота. Район җитәкчелеге озак вакыт мәгълүмати вакуумда яшәгән эшмәкәрләр белән конструктив мөнәсәбәтләр урнаштыра. Авыл хуҗалыклары тамырдан үзгәрә бара, дисәң дә була: эшкәртелә торган җир мәйданнары, савым күрсәткечләре сизелерлек арта, мотор-трактор паркы яңартыла...

Бәһаутдинов җитәкчелегендә Камышлы районы муниципалитетлар рейтингында социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре буенча лидерлар рәтенә керә. Сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, спорт системаларын модернизацияләүдә зур адымнар ясала. Район казанышларына мәктәпкәчә һәм мәктәп мәгариф учреждениеләрен төзек тоту, яңа спорт корылмалары төзү һәм мәдәни-ял итү учреждениеләрен ремонтлауны да кертергә мөмкин. Балалар өчен заманча спорт мәйданчыклары төзелә. Алар һәр авылда бар. Камышлы авылында өлкәдәге бердәнбер «Бөркет» чаңгы-биатлон комплексы төзелә.

Район җитәкчелеге эчке административ резервларны куллану белән генә чикләнми, өлкә хөкүмәте дәрәҗәсендәге проблемаларны хәл итүгә дә күп көч куя. Бу өлкәдә дә Самар өлкә хөкүмәте ярдәме белән алга китеш күзәтелә. Муниципалитет тузган һәм авария хәлендәге торак йортлардан күчерү программасында катнаша, социаль объектларга капиталь ремонт ясау, юллар төзү һәм ремонтлау эшләренә дә акча бирелә. Шулай ук торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе дә модернизацияләнә - районның торак пунктларын төзекләндерү проектлары гамәлгә ашырыла. Гомумән алганда, район башлыгының өзлексез контроле астында хакимият органнарының барлык тармаклары да - район хакимияте, җирлек администрацияләре һәм депутатлар корпусы бердәм эш алып баралар.

2019 елда район милләтара тынычлыкны ныгыту буенча Россиядә иң яхшы район булып танылды.

Милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, милли сәясәт өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеген иң яхшы оештыручы буларак Бөтенроссия конкурсында икенче урынны алган иде.

Шушы елның июнь аенда Камышлы авылының искиткеч урынында урнашкан мәйданда Бөтенроссия авыллар Сабан туе узды. Әлбәттә, Татарстан Республикасы һәм Самар өлкәсе җитәкчеләре бу җаваплы мәдәни чараны оештырып уздыруны камышлылыларның булдырачакларына ышанып тапшыралар. Һәм ялгышмыйлар. Ул бәйрәм югары дәрәҗәдә уза. Төрле төбәкләрдән килгән кунаклар, аны әле дә сагынып, зур бәя биреп искә алалар.

Заманалар катлаулы булуга карамастан, барлык өлкәләрдә дә бердәм эш алып бару нәтиҗәсендә районда бик күп иҗтимагый программалар тормышка ашырылып килә. Бүген район Бөек Җиңүнең 80 еллыгын каршыларга әзерләнә, ул илебез президенты тарафыннан Ватанны саклаучылар елы кысаларында билгеләп үтелә. Районда ел дәвамында шушы бөек датага багышланган чаралар узачак. Аларның барысы да тарихи хәтерне саклауга һәм арттыруга, күпмилләтле Россия халкының батырлыгын мәңгеләштерүгә, ватанпәрвәрлек һәм гражданлык хисләрен формалаштыруга юнәлдереләчәк.

Камышлы районыннан Бөек Ватан сугышына 6000 кеше киткән булган. Якташларыбыз Ленинград, Кырым һәм Балтыйк буенда, Белоруссиядә һәм Украинада, Польшада һәм Германиядә батырлык һәм каһарманлык күрсәтеп сугышканнар. Ул коточкыч сугыштан 3647 якташыбыз кайтмаган. Район халкы батырлыгы тылда да чагылган. Без сугыш вакытында тылда эшләгән хезмәтчәннәр батырлыгын мәңге хәтерләячәкбез.

Украина сугышына ярдәм күрсәтү дә район тормышының аерылгысыз өлеше булды. Рафаэль Баһаутдинов җитәкчелегендә Камышлы районы беренчеләрдән булып махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм җыю эшендә берләште. Фронтка мәктәп укучылары, педагоглар, хезмәт коллективлары, эшмәкәрләр һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре, крестьян-фермер хуҗалыклары җитәкчеләре, пенсионерлар булышалар. Район һәм җирлек администрацияләре МХОга китүчеләрне озатканда ярдәм оештыралар, гаиләләренә дә булышып торалар. Район халкы да махсус хәрби операция сугышчыларының ихтыяҗларын канәгатьләндерү нияте белән маскировка челтәрләр



үрәләр, шәм коялар, үлән чәйләре ясап җибәрәләр, бертуктаусыз акча җыялар. Ничек инде андый кешеләр белән горурланмаска! 2024 елда район халкы 2 млн. 86 мең сум акча җыя алды. 2022 елның октябреннән санасак - 6 млн. 400 мең чамасы. Бу акчага сугышчыларга 5 тоннадан артык гуманитар йөк җибәрелгән, һәрберсенә адреслы ярдәм күрсәтелгән, җылы әйберләр һәм аяк киемнәре, саклану чаралары, квадрокоптерлар, машина шиннары, квадрокоптерларны ачыклау детекторлары, оптик прицеллар, тавыш сүндергечләр, медикаментлар, гигиена чаралары, дизель һәм бензин генераторлары, радиоэлектрон саклану җайланмалары, 15 машина (УАЗлар, Нивалар, квадроцикллар, җиңел автомобильләр) ремонтлап тапшырылды, азык-төлек, көнкүрешне җайлаштыру чаралары һәм башка бик күп нәрсәләр...

Үзенең хезмәте белән Камышлы районы башлыгы, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең җирле бүлекчәсе секретаре Рафаэль Баһаутдинов лаеклы абруй казанды, Камышлы районы халкының үз кешесе булып танылды. Аның турында халык намуслы, оешкан һәм алдан күрүчән җитәкче, ачык күңелле кеше, дип сөйлиләр.

«Әйләнә-тирәдәге кешеләрнең минем катнашым белән яхшырак яши башлавын күрү әйтеп бирә алмаслык хисләр уята. Мин Камышлы районы халкының яхшы якка үзгәрешләрне күреп сөенүен телим. Олысы да, кечесе дә үз районы, үз авылы белән горурлансын иде. «Бу - безнең туган ягыбыз, шуңа яратабыз», - дип кенә түгел, ә районның елдан-ел байый, матурлана баруы, мул уңышлар алуы, халкының бердәмлеге белән горурлансыннар иде!» - дип теле район башлыгы.

# Рожденная в золотое время

## Самарской областной татарской газете «Бердәмлек» исполняется 35 лет

***Утром 9 января 1990 г. маленькие сетевые радиоприемники, стоявшие в каждой квартире и каждом доме, возвестили о большом событии в жизни татарского населения Куйбышевской области: решении секретариата обкома КПСС об издании областной газеты на татарском языке «Бердәмлек». Это стало итогом многомесячной работы татарского культурного центра «Туган тел» по выполнению одного из пунктов своей программы-минимум, обнародованной на первом собрании национальной и духовной общественности 21 января 1989 года в Доме молодежи.***

***Шамиль Галимов,***
*первый ответственный секретарь газеты «Бердәмлек»*

Между двумя событиями прошел почти год. В этот период областные и городские власти почти всегда и без проблем шли татарским активистам навстречу: по согласованию с ними мы начали проводить культурно-массовые мероприятия, в органах образования прошли первые встречи по вопросу открытия воскресной школы, состоялась церемония закладки символического фундамента под новую городскую мечеть… Только один вопрос повис в воздухе: о возобновлении в Куйбышевской области издания татарской газеты. Причины такого затягивания и откладывания могли быть разные. Возможно, в обкоме партии, в то время главном региональном государственном органе, памятуя о слова Ленина о том, что газета – не только коллективный пропагандист и коллективный агитатор, но также коллективный организатор, решили подождать и посмотреть, как покажет себя татарская интеллигенция в новом для всех деле. Ведь пропагандист и агитатор – это полбеды. А не захотят ли они через газету что-нибудь не то организовать, словом, как бы чего не вышло…

Мы ждали полгода. За это время наша национально-культурная организация спокойно довела до конца процедуру регистрации в областном управлении юстиции, тем временем продолжая работать строго в рамках своего устава. Поэтому всем было ясно, что в новое общественное движение пришли действительно энтузиасты национальной культуры. В большинстве своем представители технической и творческой интеллигенции, сфера интересов которых только национальная и духовная жизнь и ничего больше. Наконец, рядом с нами стояла авторитетная мусульманская религиозная организация с мудрыми аксакалами во главе, поддержку работе «Туган тел» уже в первые месяцы деятельности начали оказывать такие известные люди, как Р. Х. Ягудин, У. А. Амиров, В. Г. Мухаметшин и другие.



Все сомнения руководства города и области, по всей видимости, окончательно рассеялись после многотысячного Сабантуя 24 июня на ипподроме, когда многие куйбышевцы – представители других национальностей смогли в первый раз побывать на грандиозном, достаточно хорошо организованном татарском национальном празднике. Тогда-то «наверху» и решили, что с этой организацией можно иметь дело, и мы получили приглашение подойти на встречу.

Таким образом, сама организационная работа по созданию газеты началась 30 июня, когда представители культурного центра «Туган тел» Р. Ф. Абдулов, Р. Н. Аглиуллин, М. А. Сагиров и М. С. Ямалетдинов понесли в обком партии «петицию» с подписями более тысячи участников областного Сабантуя с соответствующим обращением к руководству области. Кандидат в редакторы будущей газеты изначально был только один – известный всему татарскому населению области Рафкат Аглиуллин, многолетний корреспондент «Волжской коммуны», а к моменту начала татарского национального движения – заместитель редактора Волжской районной газеты. Кстати, Рафкат Набиуллович с февраля 1989 года стал постоянным автором материалов о деятельности культурного центра «Туган тел» в «Волжской коммуне» и главной газете ТАССР «Социалистик Татарстан».

При контактах с руководством области мы всегда подчеркивали именно необходимость возобновления работы в Куйбышевской области татарской газеты, такая идея прозвучала в выступлении ветерана журналистики Ф. Х. Давыдова (1925–2000) на том первом собрании татарской общественности в Доме молодежи. Фаик Хайруллович, коренной горожанин, еще застал закрытую в апреле 1938 года газету «Колхозче», помнил ее сотрудников. Может быть, элемент восстановления преемственности татарской национальной печати в какой-то степени тоже способствовал положительному результату наших усилий.

...До самого Нового года шла работа по согласованию концепции газеты, ее организационной формы, штатного расписания и сметы расходов. С нами постоянно работал инструктор идеологического отдела обкома КПСС В. В. Пименов. По примеру соседнего Ульяновска, где, немного опережая нас, тоже готовились к изданию татарской газеты, мы подали необходимые расчеты. При этом предложив три варианта названия газеты – «Идель» («Волга»), «Дуслык» («Дружба») и «Бердәмлек» («Единство»). Секретарю обкома по идеологии Г. Н. Деревякину, с которым инициативная группа (к которой вскоре присоединились Ш. А. Ахмеров и Ш. Х. Галимов, а негласным членом-консультантом была завотделом «Волжской коммуны» Л. Ш. Шафигуллина) встречалась несколько раз, понравилось третье. Правда, сначала его смутило совпадение по смыслу с «Литовским движением за перестройку «Саюдис», в переводе на русский тоже означает «единство». Но в конце концов на нем и остановились.

После обкомовского постановления, 1 марта исполком областного совета народных депутатов – при активной поддержке первого заместителя председателя Г. В. Ходасевича – «продублировал» это решение, выделив соответствующие средства, фонды газетной бумаги и поручив Куйбышевскому горисполкому подобрать помещение для редакции. Тут необходимо сделать одно пояснение и уточнение. Значит, основателями газеты «Бердәмлек" стали два главных в области государственных органов власти – обком КПСС и облисполком. Надо помнить, что в советское время могло быть только так и никак иначе, ни один отдельно взятый человек при всем желании и даже наличии финансовых возможностей не мог основать, учредить газету и начать ее издание.

...С 2 марта редактору газеты пошло начисление зарплаты, остальной штат – еще пять единиц – предписывалось набрать с 1 апреля. В эти же дни редакция въехала в небольшое здание на улице Фрунзе, 103. Кроме Рафката Аглиуллина, сотрудниками газеты стали журналист газеты завода «Прогресс» Шамиль Галимов, полковник запаса, в последний период службы – лектор Политуправления Приволжского военного округа Идеал Галяутдинов, выпускница факультета иностранных языков Куйбышевского пединститута Амина Шамсутдинова, ставшая корректором и машинистка Мария Юсупова. Также была введена должность собственного корреспондента по северным районам области, где проживала основная часть наших потенциальных читателей, ее занял Мухтар Сафиуллин, по основной работе – сотрудник Клявлинской районной газеты «Знамя Родины» и ее татарского дубляжа «Ватан байрагы». Бухгалтерский учет вела Марьям Мустафина.




Весть о рождении татарской газеты мгновенно разнеслась по области, люди с нетерпением



# Счастливого пути, «Бердэмлек»!

Вышел первый номер газеты на татарском языке «Бердэмлек» («Единство») — органа Куйбышевского обкома КПСС, областного Совета народных депутатов и татарского культурного центра «Туган тел». Он поступил для розничной продажи в киоски «Союзпечати» города Куйбышева сегодня, а завтра его смогут получить и жители других городов и районов области.

Номер открывается обращением редакционного коллектива к читателям, в котором определены основные направления и цели нового издания: возрождение родного языка, национальной культуры, традиций и обычаев татарского народа, развитие его духовности, самобытности, воспитание культуры межнациональных отношений и дружбы народов Поволжья.

С выходом первого номера читателей поздравляют Куйбышевский обком КПСС, областной Совет народных депутатов, ассоциация культурных центров области «Радуга», татарский общественный центр г. Казани, а также видные деятели культуры и искусства Татарии, Куйбышевской области.

Интересные материалы найдут в газете не только взрослые, но и дети. В первом номере для них опубликованы стихи и сказки.

Газета «Бердэмлек» будет выходить раз в неделю. Следующий номер читатель получит 9 мая — он посвящается 45-летию Победы.

Желающие выписать газету могут это сделать в отделениях «Союзпечати» (индекс газеты 52382, стоимость годовой подписки — 1 рубль 56 копеек).

На снимке: первый номер газеты; редакционный коллектив нового издания — справа налево — Шамиль Галимов — ответственный секретарь, Идеал Галяутдинов — зав. отделом, Рафкат Аглиуллин — главный редактор, Аминэ Шамсутдинова — переводчик, корректор.

Фото В. Муратова.

стали ждать выхода первого номера. 24 марта на празднике Навруз во Дворце спорта авиационного завода на нее заранее подписались более 600 (!) человек.

Шрифты с татарским алфавитом для пишущей машинки и линотипных машин в Доме печати (вероятно, удивительные для молодого поколения названия) можно было найти только в Казани, их по обыкновению того времени пришлось «доставать». На помощь пришел Равиль-ага Ягудин, который был в приятельских отношениях с директором театра имени Камала Ш. З. Закировым. Через Шамиля Зиннуровича мы обратились к руководству Дома печати на Декабристов, нам совершенно бесплатно выделили два комплекта шрифтов, при этом горячо пожелав успеха в начатом деле.

Хотя все мы были уроженцами татарских сел, кто получше, кто похуже, но хорошо знали родной язык, однако понимали: в таком деле, как выпуск газеты, эти знания надо будет углублять, расширять, пополнять и совершенствовать, что приходилось делать уже потом, в режиме постоянной практики и нередко методом проб и ошибок. А первый номер газеты «Бердэмлек» был сдан в печать глубоко за полночь с 24 на 25 апреля, а на утро он был уже готов. В тот год праздник Ураза-байрам пришелся на 27 апреля. Основной тираж газеты «Бердэмлек» был роздан в этот день на Гает-намазе возле мечети на Малом тупике.

...Начало 90-х годов. То было, без преувеличения, золотое время. В обществе царило воодушевление и светлые надежды на будущее. Журналисты газеты «Бердэмлек» жили теми же мыслями. В интервью «Волжской коммуне» 24 марта, перед выходом первого номера, Рафгат Аглиуллин говорил, что «это будет еженедельник тиражом на первых порах в 12 тысяч экземпляров». А один из активистов татарского центра Мансур-ага Ямалетдинов предположил, что в скором времени газету будут получать не менее 25 тысяч семей.

В ту пору иначе и не думалось. Хотя в действительности самый высокий подписной тираж был достигнут в 6222 экземпляра – в июне 1993 года. Плюс часть газет продавались через киоски «Союзпечати». В одно время общий тираж газеты достигал восьми с половиной тысяч экземпляров. На праздниках Сабантуй и Навруз на газету в первое время мы подписывали (годовая подписка стоила 1 рубль 56 копеек) за один день до 500 человек. А в сельских районах «Бердэмлек» стали выписывать практически целыми селами. Страна тогда была еще «самой читающей в мире».

Однако в скором времени все стало меняться. Но это уже совсем другая история...

# Утыз ел динебезгә һәм халкыбызга хезмәттә

***2025 елның 1 мартында Иске Ярмәк авылы имамы Габдулла-Рамил хәзрәт МӨХӘММӘТКӘРИМнең имамлык итә башлавына утыз ел тулды.***

**«Туган тел» оешмасы**





90нчы елларда Иске Ярмәктә ачылган яңа мәчет рәисе Мирсәет Вәлиәхмәтов тәкъдиме буенча Рамил (туу турындагы таныклыкта язылган исеме шулай аның) Кәримов үзенең тормышын динебез ислам белән бәйләргә ниятли һәм Гали авылы мәдрәсәсенә укырга керә.

Мәдрәсәне тәмамлаган егет туган авылы Иске Ярмәккә кайта һәм мөәзин вазифаларын башкаруга керешә. Ярты ел да узмый, карт имам авырып китә һәм мәхәллә Габдулланы хәзрәт итеп сайлый. Унсигез яше дә тулмаган Габдулла Мөхәммәткәрим Самар өлкәсендәге 24 мәхәллә муллалары арасында иң яшь имам булып китә.

Яшьлегенә карамастан, яңа мәчетнең яңа хәзрәте эшкә җиң сызганып керешә. Ул дин гамәлләрен яхшы башкара, мәчеткә авыл картларын гына түгел, яшьләрне дә җәлеп итү өстендә бертуктаусыз эшли.

1890 елда төзелгән, ә революциядән соң мәктәп булып хезмәт иткән мәчет бинасын сүтеп, хәзерге мәчет йортына күчереп салу да җиңел эш булмаган, әлбәттә. Ләкин Габдулла Мөхәммәткәрим бу ниятендә дә берүзе калмый, теләктәшләр таба һәм тиздән элеккеге мәчет диварлары эчендә якшәмбе мәдрәсәсе эшли башлый.

2007 елдан бирле Ярмәк балалары Казанда уздырылып килүче дини бәйгеләрдә катнашалар, еш кына призлы урыннар алып кайталар. Ә теләгән кеше Казан, Уфа шәһәрләренә, Биләр, Болгар музей-тыюлыкларына барып кайта ала. Бу чаралар да имам катнашыннан һәм оештыруыннан башка үтми, әлбәттә.

Зиратны тәртиптә тотуны да үз өстенә алган ул. Халыктан акча җыеп, башта иске зиратка өстәп, яңа 5 гектар җиргә койма коела, ә тагын бер елдан соң бөтен зиратның да рәшәткәләре яңартыла, буяла. Шул ук вакытта борынгы каберлекләр корыган агачлардан, чүп-чардан арындырыла. Габдулла хәзрәт шимбә өмәләрен оештырган вакытта искеярмәклеләр үз туганнарының гына түгел, караучысыз калган каберлекләрне дә төзекләндереп торалар.

Габдулла Мөхәммәткәрим фикердәшләре белән бергә авыл тирәсендәге каберлекләрне барлады. Мәсәлән, Юкәле тау өстендәге Изгеләр кабере өстенә истәлек ташы куелды, тирә-ягына агачлар утыртылды. Гүр ияләре тынычлап ятсыннар өчен Сабан туе урыны Юкәле таудан башка җиргә күчерелде.

Урман эчендә җирләнгән Корбангали кабере дә хәзер һәркемгә билгеле. Ел саен аның янына бер төркем картлар барып, дога укыйлар, каберлекне тиешенчә карап, чистартып китәләр.

Габдулла Мөхәммәткәримнең тагын бер мавыгуы бар әле. Ул – Иске Ярмәк авылының тарихы һәм анда яшәүче кешеләрнең шәҗәрәләрен төзү. 1997 елда ук аның ярдәме белән авылның 260 еллыгына багышланган “Иске Ярмәк авылы тарихы” дип аталган брошюра бастырылган иде. 2018 елда аның киңәйтелгән варианты да чыкты.

Бу китапны язуда бөтен авыл катнашты, дип әйтергә була. Чөнки имам тырышлыгы белән һәркем үз нәселен, үз шәҗәрәсен барлаган, токымдагы иң танылган шәхесләр билгеләнгән, әзер материаллар тарихчы Фәрит Шириаздановка тапшырылган иде. Фәрит әфәнде аларны системага салды.

Габдулла хәзрәт мәчет эшләренә генә йомылып ятмый. Ул балалар өчен Сабан туйлары оештыруда актив катнаша. Хәзрәт – Мәдәният йорты каршындагы үзешчән сәхнә түгәрәге әйдаманнарының берсе.

Яшьли динебез юлына басып, аннан тайпылмыйча, Камышлы районы халкына ярдәм күрсәтеп яшәүче Габдулла хәзрәткә киләчәктә дә игелекле гамәлләре белән күпләргә үрнәк, таяныч, киңәшче булып, озак еллар гомер итәргә язсын иде.

Аллаһы Тәгалә аңа исәнлек-саулык, гаилә сәгадәте муафыйк кылсын. Хәерле хезмәтендә уңышлар юлдаш булсын.

# “Балалар татар телен яратып үзләштерәләр икән, бу - минем өчен олы бәхет”

***Мәрдегали кызы Гөлфия Таҗетдинова белән Самар шәһәренең “Яктылык” мәктәбендә узган өлкә татар теле олимпиадасында таныштык без. Тыйнак, мөлаем, нурлы йөзле, озын күлмәк кигән, яулык бәйләгән бу ханым шунда ук игътибарымны җәлеп итте. Сүз кушкач, аның Камышлы районының Яңа Усман авылыннан килүе ачыкланды. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, ул укучыларын олимпиадада катнашырга алып килгән икән. Без аның белән рәхәтләнеп татарча сөйләшеп киттек, яшь арабыз бер ел гына булгач, бик тиз уртак тел дә таптык. Йомшак тавышлы, зыялы, сүзен салмак кына, үлчәп кенә сөйләүче Гөлфия ханым белән аралашканда чын укытучы нәкъ шундый булырга тиеш, дип уйлап куйдым. Үзе дини кеше, мәдрәсәдә гыйлем алган, шәригать кануннарын үтәп яши.***

***Миләүшә Газимова***



Милләттәшебез менә инде 22 ел буена балаларда татар теленә мәхәббәт тәрбияли, аның бай, аһәңле булуын, ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген төшендерә. Шулай ук ул күп еллар рус теле һәм әдәбияты дәресләрен дә алып бара.

Оренбург өлкәсенең Северный районында урнашкан Бакай авылында туып-үскән Гөлфия мәктәптән соң Самар дәүләт педагогика университетының милли бүлегендә белем ала һәм рус, татар телләрен укытырга хокуклы белгеч булып чыга. Тормышын Яңа Усман егете белән бәйләп, иренең туган авылында төпләнгәч, мәктәпкә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып урнаша. Ә тора-бара рус теле дәресләрен дә алып бара башлый.

Гөлфия даими рәвештә һөнәри сыйфатларын, профессиональлеген үстерү өстендә эшли, Казан федераль университетында укып, татар теле һәм әдәбияты укытучысы дипломын ала.

– Бу һөнәр турында балачактан хыялландым мин. Күрше-тирә балаларны тезеп утырта идем дә, кулыма күрсәткеч таяк (указка) тотып, имеш дәрес алып бара идем, – дип елмая әңгәмәдәшем.

Бертуган апасының, әтисе белән әнисенең сеңелләренең укытучы булулары да аңа тәэсир итмичә калмагандыр.

– Телебез әти, әни, дип татарча ачылды, авыз тутырып татарча сөйләшеп үстек без. Мәктәптә дә мин татар теле дәресләрен аеруча яраттым. Ана телебез бит ул, җанга газиз, күңелгә якын. Татар теле укытучысы булуыма шатланып туя алмыйм. Балаларда туган телебезгә кызыксыну уятыр, мәхәббәт тәрбияләр өчен бар көчемне куеп эшлим.

Тик шунысы кызганыч – татар теле һәм әдәбияты дәресләренә икесенә бергә атнасына бары тик бер сәгать кенә каралган. Тиешле күләмдә белем бирер өчен бу ифрат та әз. 10 - 11нче сыйныфларда исә татар теле бөтенләй укытылмый, – дип уртаклаша Гөлфия.




*– Ә укучылар ана телен ничек үзләштерәләр?* – дип кызыксындым аңардан.

– Төрлесе төрлечә. Гаиләләрендә татарча аралашкан балалар җиңел өйрәнәләр, алар белән рәхәтләнеп татарча сөйләшәсең. Ә менә өйләрендә туган тел яңгырамый икән, мондый укучыларга төшенүе авыр инде. Аннары, кайберәүләр кызыксынып, тырышлык куеп укыйлар. Кайсыберләре исә татар телен кирәксенмиләр. Ә бит теләк булуы бик мөһим. Менә, мәсәлән, мәктәпне тәмамлаган бер укучым – чеп-чи урыс кызы татар телендә шундый яхшы сөйләшә иде, исләрең китәр! Без аның белән гел татарча аралаша идек. Миңа матур итеп, татар телендә Гөлфия апай, дип эндәшә иде ул. Теләк булгач, булдырасың, дип әйтәсем килә. Татар балалары да туган телләрен шулай ук кирәксенсеннәр иде. Ә моның өчен эшне, әлбәттә, гаиләдән башларга. Балада сабый чактан, бишектән үк ана теленә мәхәббәт тәрбияләү мөһим. Ул татарча яхшы белсен өчен гаиләдә һәрвакыт туган тел яңгырарга тиеш. Бигрәк тә бала күп вакытын әти-әнисе, әби-бабасы белән уздыра бит. Ә без – укытучылар укучыларга телне дәрес кысаларында гына укытабыз. Бигрәк тә бер сәгать эчендә аларга нәрсә генә өйрәтеп өлгерик икән, дип аптырыйбыз.

Хәзер хәтта авыл балаларының да рус теленә күчүе, әлбәттә, күңелне борчый.

*– Укучыларыңда татар теленә кызыксыну уятыр өчен нинди ысуллар кулланасың?*

– Моның өчен дәресләрне кызыклы, мавыктыргыч итеп үткәрергә тырышам. Аларны заманча технологияләр, иллюстратив материаллар белән баетам. Кечерәк сыйныфларда татар мультфильмнарын күрсәткәлим. Өлкән классларда аудио һәм видеоязмалар кулланам.

Менә татар язучыларының, шагыйрьләренең әсәрләрен дә укысалар иде дә бит, әмма бездә әдәбият дәреслекләре юк шул. Бу бер зур проблема булып тора.

*– Ата-аналар балаларының татар телен өйрәнүләрен телиләрме?*

– Теләмиләр, дип әйтеп булмый, чөнки бу очракта алар тиешле гариза язарлар иде. “Балабыз татарча белми бит, русча гына сөйләшә”, – дип борчылучылар да бар, әмма никтер үзләре нарасыйлары белән ана телендә аралашмыйлар.

Иң беренче чиратта, кешеләрдә милли үзаңны үстерү өстендә эшләргә кирәктер. Ә бүгенге көндә, кызганычка, үзләре дә туган телләрен кирәксенмәүче һәм инде тиешенчә аны балаларына да өйрәтмәүче татарлар күп. Ә бит тел бетсә, халык бетә.

*– Хезмәтеңдә тәрбия мәсьәләләре нинди урын алып тора?*

– Мин һәр дәрестә әз генә булса да тәрбия турында сөйләп китәм. Сыйныф җитәкчесе буларак та моңа зур игътибар бирәм. Төрле мисаллар китереп, лаеклы кешеләрне үрнәккә куеп, укучыларымда рухый-әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә тырышам. “Балачакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас”, – дигән бит бөек галимебез Ризаэтдин Фәхретдин.

Балаларны иманлы, инсафлы итеп тәрбияләүдә диннең әһәмияте зур. Шуңа күрә даими рәвештә исламга нигезләнгән тәрбияви әңгәмәләр дә үткәрәм.

*– Укытучыга нинди сыйфатларга ия булу мөһим?*

– Үз фәнен яхшы белергә, киң күңелле, сабыр, балаларга карата мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга, бөтен укучыларын бертигез күрергә тиеш.



Ришат һәм Гөлфия Таҗетдиновлар

Шулай ук укучыларга ачык йөз күрсәтергә кирәк. Эчең тулы ут янса да, мәктәп бусагасын атлап кергәч, йөзеңдә елмаю балкысын. Балалар безнең начар кәефне күрергә тиеш түгел.

***– Хезмәтеңнән канәгатьме?***

– Сүз дә юк! Үземне башка һөнәрдә күз алдыма да китерә алмыйм. Балаларны өзелеп сөям бит мин. Бигрәк тә укучыларың: “Апа, без сезне яратабыз”, – дип торганда ничек канәгать булмыйсың ди инде! Пандемия вакытында читтән торып укытканда үзләрен бик сагына идем.

Аннары, балаларга газиз ана телебезне өйрәтүем зур ләззәт китерә. Ә инде алар аны теләп, яратып үзләштерәләр икән, бу – минем өчен олы бәхет.

***– Татар теленең киләчәген ничек күзаллыйсың?***

– Барысы да үзебездән генә тора! Ана телендә аралашсак, аны балаларыбызга, оныкларыбызга өйрәтсәк, милли үзаңны үстерү өстендә эшләсәк, киләчәге булыр, Аллаһы теләсә.

***– Коллективыгызда нинди мөнәсәбәтләр хөкем сөрә?***

– Оста һәм зирәк җитәкче булган директорыбыз Гүзәл Камил кызы Маннапованың кул астында бердәм булып, киңәшләшеп, ярдәмләшеп эшлибез. Мәктәпкә урнашкач, беренче мәлләрдә хезмәттәшләрем миңа бик булыштылар. Хәзер дә гел хуплап торалар. Барысына да бик рәхмәтлемен.

***– Гөлфия, гаиләң турында да әйтеп үтсәң иде.***



Гөлфия ире һәм уллары белән

– Ирем Ришат белән 24 ел бергә гомер итәбез. Каенатам Рәшит, каенанам Мәдхия белән бер йортта яшибез. Мөнәсәбәтләребез бик әйбәт, зур, тату гаилә без.

Әлхәмдүлилләһ, үз әтием Мәрдегали белән әнием Әлфия дә исән-саулар. Безгә лаеклы тәрбия биргәннәре өчен мин үзләренә бик рәхмәтле.

Ирдән уңдым мин, Раббыма мең шөкер, һәр адымда аның ярдәмен тоеп яшим. Без аның белән гел бергә, бөтен эшне бергәләп эшлибез. Ул да дин юлында, бергә авылыбыз мәдрәсәсендә белем алдык.

Ике малай үстердек. 23 яшьлек Рөстәм безнең белән тора, авылда нефть оешмасында эшли. Кече улыбыз Рифатка 20 яшь, ул Самарда инженер хезмәтен башкара.

***– Балаларыгыз татар телен беләме?***

– Әйе, сабый чактан татарча сөйләшеп үстеләр алар. Гомумән, гаиләбездә ана теле генә яңгырый. Балалар бакчасына йөргән чакларында русча сөйләшергә маташканнар иде. “Мин мама түгел, мин – әни”, – дип бер әйтүем җитте үзләренә.

***– Синең өчен кемнәр үрнәк булып тора?***

– Мине дини мохиттә тәрбияләгән, үгет-нәсыйхәтләрен күңелгә сеңдергән әби-бабайларым, тормыш кыйммәтләрен аңлатып үстергән әти-әнием, тирән белем биргән укытучыларым, акыллы киңәшләре белән ярдәм итүче хезмәттәшләрем.

***– Кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсең?***

– Миһербанлы, кызганучан, арттан сөйләп йөрмичә, күзгә карап, турыдан-туры әйтүчеләрне якын күрәм.

***– Тормышыңны яңадан башларга туры килсә, берәр нәрсәне үзгәртер идеңме?***

– Юк! Аллаһы Тәгалә биргәненә канәгать булып, бәхетле гомер кичерәм мин. Иртән ашкынып яраткан эшемә барам, кичен ашкынып газиз гаиләм янына кайтам, әлхәмдүлилләһ.

***– Тәҗрибәле мөгаллимә буларак, яшь укытучыларга нинди киңәшләреңне җиткерер идең?***

– Түземле булыгыз, авырлыклардан курыкмагыз, дияр идем. Һәр хезмәтнең үз катлаулыклары бар. Чыдамлы булмасаң, эштә дә, тормыш көткәндә дә кыенга туры киләчәк. Татар халкы юкка гына: “Сабыр төбе – сары алтын”, – дип әйтмәгән бит инде.

Балаларны яратып, хезмәтләрен тырышып башкарырга киңәш итәр идем. Шулай булганда, укучылар да мәхәббәт белән җавап бирер, эшләре дә үзләренә ләззәт китерер.

*Ул - яраткан әни, кадерле тормыш иптәше, үрнәк әби һәм тугры апа.*

*Шуның өстенә берничә буын балаларга белем һәм тәрбия биргән ихтирамлы укытучы.*

*Сүзебез Денис авылында туып-үскән, шушында тормыш итеп, утыз өч ел гомерен мәктәпкә һәм балаларга багышлаган Нурсинә Һадый кызы Хәмәтшина турында.*

*Олылар белән дә, яшьләр белән дә уртак тел табып, үз кеше була белә ул. Бу инде табигатьтән бирелгән сәләт тә, еллар буе тупланган тәҗрибә дә.*

*Мәктәптән китүенә әле бер ел да юк, ә инде аны укучылар да, хезмәттәшләре дә бик сагыналар. “Мәктәпне сездән башка күз алдына китерә алмыйбыз”, - диләр.*

*Бу чынлап та шулай. Нурсинә ханым канаты астында тәрбияләнүче буларак, шуны әйтә алам - уку сәгатьләреннән тыш махсус түгәрәкләр оештырып, гаилә мәшәкатьләрен калдырып, укучылары янына ашыга иде ул.*

*Шул рәвешле күп кенә талантлы балаларга иҗатка юл ачты Нурсинә апа. Үз милләтен яратучылар, татар әдәбиятын якын итүчеләр булып үстеләр аның тәрбияләнүчеләре. Укучыларыбыз игътибарына Нурсинә ханым Хәмәтшина белән үткәрелгән әңгәмәне тәкъдим итәбез.*

**Лилия Галиуллина**



# “ҺӘР САМИМИ КҮЗЛӘРДӘ ШӘХЕС КҮРДЕМ МИН”

– ***Нурсинә апа, үзегез турында сөйләп китегез әле. Балачагыгыз, мәктәп еллары кызыксындыра.***

– Мин Денис авылында күп балалы гаиләдә бишенче бала булып үстем. Әти-әнием колхозда эшләделәр. Авылыбызның урта мәктәбендә белем алдым.

– ***Ни өчен нәкъ укытучы хезмәтен сайларга булдыгыз?***

– Бу һөнәр турында балачактан хыялландым мин. Икенче сыйныфта белем алганда укытучыбыз Роза Әхмәт кызы Гыймадиева безгә, укучыларына, кем булырга телисез, дигән сорау бирде һәм безнең җавапларны магнитофонга яздырды. Мин шул вакытта ук: «Укытучы булам!» - дигән идем. Роза апа бу һөнәргә мәхәббәт уятучыдыр, мөгаен.

Хыялымны тормышка ашырырга дип, Казан дәүләт педагогика институтында укыдым һәм туган авылыма эшләргә кайттым.



Нурсинә Һадыевна тормыш иптәше һәм балалары белән



Оныгы Роберт белән



Равил һәм Нурсинә Хәмәтшиннар

Миңа тирән гыйлем биргән укытучыларыма бик рәхмәтлемен. Барчасын да хөрмәт итәм. Үземне укыткан укытучылар белән эшләргә дә насыйп булды. Бу - зур бәхет, дип саныйм.

Балаларны бик яратам мин. Аларны сөймәсәң, бу һөнәргә килеп булмый. Һәр самими күзләрдә шәхес күрдем мин.

– ***Тормышыгызның кайсы чорына яңадан әйләнеп кайтыр идегез?***

– Мәктәптә эшли генә башлаган вакытларга. Зур хыяллар белән хезмәткә керешкән, алда күп мөмкинлекләр көткән бәхетле вакыт иде ул.

– ***Сез канәгать калган иң зур эшегез бармы?***

– Әлбәттә, бар. Яраткан укучыларым ярдәмендә без мәктәптә беренче музей оештырдык. Алтын куллы егетләрем ремонт эшләрендә бик ярдәм иттеләр. Стендлар элдек, экспонатлар җыйдык.

Бердәмлектә, тырышып эшләдек без. Бу хезмәтебез - киләчәк буынга калдырган мирас.

Хәзерге ваккытта музей авыл Мәдәният йортының икенче катында уңышлы эшләп килә.

– ***Сезнең өчен нинди хатын-кызлар үрнәк булып тора?***

– Гаилә корып, тәртипле балалар үстергән, хезмәтләрендә - зур уңышларга, тормышта югары дәрәҗәләргә ирешкән гүзәл затларыбызга сокланам мин.

– ***Укытучының ярты гомере мәктәптә уза. Ә бит әле үз балаларыңны тәрбияләргә дә кирәк, авыл җирендә хуҗалык мәшәкатьләре дә бихисап.***

– Хатын-кызлар гаиләне беренче урынга куярга тиеш, дип саныйм мин. Әмма мәктәп, укучылар дип җан атып йөргәндә, гаилә икенче урынга да калгалады инде.

Әле дә ярый, үз балаларым мәктәптә гел янымда булдылар. Анда - укытучы, өйдә әни булырга өйрәттеләр алар мине.

Мәктәптә бик яратып хезмәт куйдым мин, ә гаиләм эшләр өчен илһам биреп торды.

– ***Балаларны милләтпәрвәрләр итеп ничек үстерергә?***

– Сабый чактан татар телендә әкиятләр сөйләп, бишек җырларын көйләп үстерергә, үзләре белән һәрвакыт татар телендә аралашырга кирәк.

Ана теленә, милләтебезгә мәхәббәтне кечкенәдән сеңдерү мөһим.

– ***Балалар үз гаиләләрен коргач, рольләр артып китә. Барлык рольләрне дә тиешенчә башкарам, дип әйтә аласызмы?***

– Әйе, хәзер балалар үз тормышлары белән яшиләр инде. Аларның кайтканнарын түземсезлек белән көтеп алабыз. Көн дә сөйләшеп торсак та, оныгымны сагынам. Әби булуы бик рәхәт! “Әббә” дип кочаклап алуы җанга май булып ята.

Бар рольләремне дә тиешенчә башкарам (көлә)! Яхшы әни һәм әби булырга тырышам. Кулыбыздан килгәнчә ярдәм итәсе килә.

– ***Укытучы хезмәте авыр. Тормыш иптәшегез сезне хуплап яшәдеме?***

– Ирем Равил дә, балалар да һәрвакыт ярдәм итеп тордылар. Балаларым укучылар белән бергә биюләр, җырлар өйрәнәләр һәм төрле конкурсларда, фестивальләрдә яратып катнашалар иде.

Тормыш иптәшем бик матур җырлый. Авыл Мәдәният йортында ул җырлап, мин шигырь сөйләп, рәхәтләнеп бергә чаралар үткәрә идек.

– ***Яшь буынга һөнәр сайлау буенча нинди киңәшләр бирер идегез?***

– Иң беренче чиратта, күңеленә якын булган һөнәрне сайлау мөһим.

Үз осталыгыңа да игътибар итәргә кирәк. Кулыңнан килгән эшне башкару – күңелгә ял.

Нинди һөнәр сайласалар да, яшь буынга мин бары тик уңышлар телим.

Тормышта үз юлыңны табып, хезмәтеңне яратып башкару - зур бәхет ул, – дип тәгәлләде әңгәмәбезне мөлаем йөзле, сүзгә тапкыр, киң күңелле, нур сибүче Нурсинә апа.

***Тәртипле, әдәпле, тәрбияле кешеләр авыл күрке булып торалар. Шушындый шәхесләр исемлегенә кергән Рөстәм Гомәр улы һәм Камилә Камил кызы Шәйхетдиновлар да - Похвистнево районы Гали авылының күркәм, тырыш, үрнәккә куярлык яшь гаиләләренең берсе.***

***Миләүшә Газимова***

# САБЫЙЛАРДАН ҖӘННӘТ ИСЕ КИЛӘ



Яшь булсалар да, Рөстәм белән Камиләнең дүрт балалары бар инде.

– Кызыбыз белән улларыбыз – Раббыбыз биргән иң зур бүләк, алар – өйнең яме, тормышыбызның мәгънәсе, безнең өчен олы бәхет.

Сабый – Җәннәт нигъмәте ул. Аңардан Җәннәт исе килә, дип юкка гына әйтмиләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. дә: «Балалар – тормыш чәчәкләре. Балалар – Җәннәт күбәләкләре», – дигән бит, – дип олуг сөенеч белдереп сөйлиләр бер-бер артлы туган балаларын өзелеп яратучы, һәрберсенә тиешле игътибар биреп үстерүче Шәйхетдиновлар.

– Мин беркайчан да күп балалы әни булырмын дип уйламаган идем. Аллаһы Тәгалә миңа шундый дәрәҗә бүләк итте, һәм мин моңа шатланып туя алмыйм.

Эчке тойгыларымны шагыйрә Гөләра Шәрипованың шигъри юллары ачык чагылдыра:
*"Иң бәхетле мизгел тормышыңда -*
*Сабыеңны кулларыңа алу.*
*Җәннәт исе килгән җимешеңне*
*Назлап кына күкрәгеңә салу",* – дип елмаеп, куанып сөйли 31 яшьлек Камилә.

Беренче баласын 21 яшендә тапкан ул. Олы уллары Самирга быел 11 яшь тулачак. Кызлары Ясминәгә – 10, Исламга 9 яшь булачак. Ә иң кечкенәләре Данияр әле ике яшен тутырмаган.

Шәйхетдиновлар нарасыйларын бергәләшеп үстерәләр. Капитан званиесендә полициядә хезмәт итүче Рөстәмнең (Чечнядагы сугыш хәрәкәтләрендә катнашучы) вакыты тыгыз булуга карамастан, ул да кызы белән улларына тиешлечә игътибар бирә.



– Ирем эш кешесе булгач, әлбәттә, балаларыбыз күбрәк вакытны минем белән уздыралар. Әмма ул да аларны тәрбияләүдә актив катнаша, миңа һәрвакыт ярдәм итә. Малайлар гел әтиләре янында бөтереләләр, аңа йорт эшләрендә булышалар. Рөстәм үзләрен хезмәткә өйрәтә.

Ясминә инде күбрәк минем янымда. Бергәләп ашарга пешерәбез, өйләр җыештырабыз, савыт-сабаны да юыша ул, кечкенә энесен дә карый. Хәер, улларыбыз да Даниярга күз-колак булып торалар.

Әлхәмдүлилләһ, балаларыбыз мәктәптә яхшы укыйлар, тырышалар, өй эшләрен үзләре эшлиләр. Малайлар грек-рим көрәше белән шөгыльләнәләр. Кызыбыз бию түгәрәгенә йөри, – дип сөйли Камилә.

***– Хәләл җефетең өметләреңне аклыймы?*** – дип кызыксындым аңардан.

– Аллаһыга шөкер, Рөстәм мине бәхетле итә, яхшы мөнәсәбәт күрсәтеп яши.

Аның белән аралаша башлагач, шунда ук йөрәгемә ятты ул. Төпле гаиләдән булуын беләидем. Бианам Кәүсәрия безне математикадан укытты, зыялы, саф калебле, пакь күңелле кеше, балаларына да лаеклы тәрбия биргән.

Рөстәм кыю ир-ат булса да, күңеле йомшак аның, бик яр-

дәмчел, кешелекле, миһербанлы, ышанычлы, максатка омтылучан. Гаиләсен саклап-яклап яши, безнең терәгебез, таянычыбыз. Балаларыбызга яхшы үрнәк күрсәтә.



Ирем миннән ун яшькә олырак, әмма без уртак тел табып яшибез. Аның акыллы сүзләренә һәрвакыт колак салам. Ул да минем фикеремне исәпкә ала, киңәшләшеп гомер итәбез, әлхәмдүлилләһ. Хәләл җефетемә рәхмәтлемен.

***– Бәхетле булыр өчен ир белән хатын арасында мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш, дип саныйсың?***

– Иң беренче чиратта, бер-береңне хөрмәт итү, сабыр булу кирәк. Юл куя белергә. Бер-береңнең сүзен тыңларга. Мәсьәләләрне уртага салып, бергәләп хәл итәргә.

***– Пәйгамбәребез с.г.в.: “Балаларыгызга кадер-хөрмәт күрсәтегез, аларны асыл кешеләр итеп тәрбияләгез”, – дип әйткән. Кызыгыз белән улларыгызга нинди үгет-нәсыйхәтләрегезне җиткерәсез?***

– Олыларны хөрмәт итегез, кешегә начар сүз әйтмәгез, берсен дә рәнҗетмәгез, дип вәгазьлибез.

Туганлык җепләрен сакларга өйрәтәбез. Сез – дөньяда бер-берегезгә иң якын кешеләр, үзара ярдәмләшеп, хөрмәтләшеп, яратышып, тату яшәргә, бер-берегезне сакларга, якларга кирәк, дип тукып торабыз.

***– Акыллы балалар тәрбияләүнең сере нидә?***



– Аларны яратырга, үзләренә җитәрлек игътибар бирергә кирәк. Шул очракта алар бәхетле дә, тәртипле дә, тәүфыйклы да булачак. Мәхәббәттән күп нәрсә тора, балаларга сөюеңне күрсәтеп тору мөһим.

***– Нарасыйларыгызны тәрбияләүдә кемнәр булыша?***

– Әниләребез Кәүсәрия белән Зөлфирә бик тә ярдәм итәләр.

Кәүсәрия әнием белән бер авылда яшәгәч, балалар күбрәк аның янында инде. Ул аларга догалар, намаз уку тәртибен өйрәтә, математика буенча өй эшләрендә булыша, әлеге фәннең нечкәлекләренә төшендерә.

Минем әнием Зөлфирә Балыклы авылында яши, Камышлыда теш табибы кабинетында шәфкать туташы булып эшли. Ул да ял көннәрендә еш кына безгә килә, оныклары белән шөгыльләнә, бигрәк тә аларда китап укуга мәхәббәт тәрбияли.

Гали авылында торучы әтием Камил дә безгә зур ярдәм күрсәтә.

Без аларга бик рәхмәтлебез. Әби-бабайлар тәрбиясен алып үскән бала – бәхетле бала ул, чөнки алар – акыл изләре, катлаулы тормыш юлын үткән тәҗрибәле кешеләр, һәр сүзләре алтын бәртегенә тиң.

Кызыбыз белән улларыбызның шундый бабай белән әбиләре булуына сөенеп туя алмыйбыз.

***– Син җитди, таләпчән яисә йомшак холыклы әниме?***

– Йомшаклык та кирәк, таләп-



чәнлек күрсәтмичә дә булмый. Иң мөһиме – икесенең дә чамасын белү тиешле.

***– Бала үз ризыгы белән туа, диләр. Син моның белән килешәсеңме?***

– Әйе, хак сүзләр бу. Аллаһы Тәгалә Үзе биргән баланы ризыктан, ярдәменнән калдырмый.

***– Балаларыгыз үскәч, аларны кем булып күз алдына китерәсез?***

– Без табиб булуларын телибез. Әмма моңа мәҗбүр итмәячәкбез. Үзләре карар кылырга тиеш, дип саныйбыз. Нинди генә һөнәр сайлап алсалар да, без аларны хуплаячакбыз. Иң мөһиме – үзләренә ошасын, күңелләренә ятсын.

Әлегә малайларыбыз, әтиләренә карап, полиция хезмәткәре булырга телиләр. Ә кызыбыз, Кәүсәрия әбием кебек, укытучы булачакмын, ди.

Әмма бу балачак хыяллар гына бит әле, үсә төшкәч, әлбәттә, фикерләренең үзгәрүе мөмкин.

Безнең өчен исә иң әһәмиятлесе шул ки, исән-сау, бәхетле булсыннар.

***– Кайбер хатын-кызлар, үстерүе җиңел түгел, дип, бер бала белән генә чикләнеп калалар. Бу турыда ни дияр идең?***

– Алда әйтеп үткәнебезчә, һәр сабый үз ризыгы белән туа. Аллаһы Тәгалә дөньяга килгән баланы Үз ярдәменнән калдырмый.

Аннары, бер сабыйны үстерүе, киресенчә, авыррак, дип саныйм мин. Бернichә бала бер-берсенә иптәш тә, күз-колак та була, бергәләп уйныйлар, бергәләп дәресләр эшлиләр алар, бер-берсенә ярдәм итәләр.

Гүзәл затларыбыз шуны истән чыгармасалар иде – хатын-кызларга Аллаһы Тәгалә ана булу вазифасын йөкләгән. Дин буенча без – нәселне дәвам итүчеләр. Ислам карашынча, дөньяда иң күркәм, иң мөкатдәс гамәл – сабыйлар тудыру һәм иң саваплы эш – балалар тәрбияләү.

Гомумән, ана булуның әҗере зур аның. Кыямәт көнендә, мөмкинлеге булып та, үзе теләп бала тапмаган хатын-кыз сабый тудырган хатын-кыздан түбәнрәк дәрәҗәдә була, ди. Шуңа күрә кызларга, кияүгә чыгып, бәби тудыру хәерле.

***– Күп балалы гаиләләргә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтеләме?***

– Әйе, ай саен түләүләр каралган, балаларга музейларга, ял итү паркларына, зоопаркларга, күргәзмәләргә керү бушлай, шулай ук җир кишәрлеге, ташламалы ипотека кредиты бирелә һәм башка төрле юнәлешләрдә ярдәм күрсәтелә.

***– Камилә, син өйдә бала карап кына утырмыйсың, яраткан мавыгуларың да бар дип беләм.***

– Әйе, мин – фитнес-тренер. Хатын-кызлар белән батутта тренировкалар үткәрәм. Батутта сикерүябыгыр өчен дә, гомумән, сәламәтлек өчен дә файдалы.

Шулай ук авылыбызның “Ялкын” төркемендә җырлыйм. Казанда “Кәмит Җәвит” тапшыруында булып кайттык. Анда җырлар башкардык, мәзәкләр сөйләдек.

Төрле конкурсларда, фестивальләрдә дә катнашабыз.

Киләчәктә, Аллаһы насыйп итсә, авылыбызда балалар өчен бию түгәрәге оештырырга ниятлим. Үзләренә татарча биюләр өйрәтергә телим.

Балалар белән эшләр өчен махсус белемем бар – мәктәптән соң мин Похвистнево шәһәрендәге педагогика көллиятендә башлангыч сыйныфлар укытучысы һәм тәрбияче һөнәрләрен үзләштердем.

Мондый түгәрәкне нарасыйларга татар биюләрен өйрәтү максатыннан гына түгел, шулай ук аларда ана теленә мәхәббәт тәрбияләү, үзләрен татар телендә аралаштыру теләгеннән оештырасым килә. Чөнки, кызганычка, хәзер татар авылларында да малайлар, кызлар күбесенчә урысча сөйләшәләр.

Аянычлы хәл инде бу, моңа йөрәк әрни. Газиз телебезне ничек булса да саклап калырга иде. Тел югалса, милләт югала бит. Ә без – бөек халык, без яшәргә тиеш! Әгәр дә телебезне саклауга, үстерүгә әз генә булса да үз өлешемне кертә алсам, мин бик шат булыр идем.

**– Синеңчә, хатын-кызның бәхете нидә?**

– Күп балалы ана булуда, ире белән яратышып, хөрмәтләшеп яшәүдә.

# БӘХЕТ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМЕ?!

***Яшәү - мизгел, сөю - мәңгелек, диләр. Дөрестән дә шулай бит. Кеше гомер баскычыннан югарырак менгән саен үзенең кире әйләнеп кайтмас яшьлек еллары, сөйгән яры белән кулга-кул тотынышып, гаилә дип аталган дәүләтендә сабыйлар тудырып үстерүләре, ә бераз гомер үткәч, сөенә-сөенә беренче оныкларын кулларына алып яратуларын сагынып искә ала һәм инде, гомер көзенә килеп кергәч, тормышта ирешкән уңышларына шатланып, нәтиҗә ясар чак та килеп җиткәнлеген аңлап ала.***

***Нурсинә Хәкимова***




Похвистнево районындагы Яңа Мансур авылында гомер итүче танышларым – Насыйх ага һәм Мөгаззәмә апа Гарифуллиннар белән телефон аша аралашкан вакытта алар да үзләренең нәкъ менә шундый сөенечле вакыйгалары белән уртаклаштылар.

– Сеңелем, бергә гомер итүебезгә 65 ел тулу уңаеннан күркәм юбилеебызны үткәреп җибәрдек бит әле.

Безгә ихтирам күрсәтеп, авылыбыз башлыгы Илмир Гыйззәтуллин хезмәткәрләре белән бергә өебезгә килделәр һәм олуг бәйрәмебез белән котладылар. Аннан соң Похвистнево районы администрациясе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Сергей Черкасовның Рәхмәт хатын һәм күчтәнәчләр тапшырдылар.

Безне зурлап килүләре өчен аларга үзебез һәм балаларыбыз исеменнән олы рәхмәтләребезне әйтәбез!

Билгеле, шундый сөйләшү булып узгач, мин түзеп кала алмадым, кулыма каләмемне алып, шушы юбилярлар турында язарга, укучыларыбызны алар белән якыннанрак таныштырырга уйладым.

Насыйх эшче-крестьян гаиләсендә туып-үскән. Ә Мөгаззәмәнең әти-әниләре, бәхет эзләп, яшьли чит җирләргә чыгып киткәннәр. Ләкин аларга тынычлап яшәү мөмкинлеге бирелми, илебездә Бөек Ватан сугышы башлана. Яшь парга, күптән түгел дөньяга аваз салган сабыйлары Мөгаззәмәне алып, Чита шәһәреннән яңадан туган авыллары Яңа Мансурга әйләнеп кайтырга туры килә.

Авылдан ирләр бер-бер артлы фронтка китеп беткәч, Хәерлафа апага, кызын әбисе тәрбиясенә калдырып, башка хатын-кызлар белән беррәттән колхоздагы бөтен авыр эшләрдә бил бөгәргә туры килә.

Зур авырлыклар аша бирелгән Бөек Җиңү килеп җиткәч, сугыш уты сүнеп, илебездә тынычлык урнашкач, авылга ирләр кайта






башлый. Ә Бәкергә бары тик 1947 елда гына туган ягына әйләнеп кайту бәхете насыйп була.

Сугыш тәмамланса да, авылда тормыш алып баруы җиңел булмый. Кая карама - юклык, хәерчелек хөкем сөрә. Күмәк хуҗалык тормышы да артта калган, ягарга – утын, ашарга – ризык, киярргә кием булмавы үзәккә үтә.

Бүгенге көндә җитеш тормышта яшәүче Мөгаззәмә апа ул елларны күз яшьләрсез искә ала алмый. Кечкенә чагында әнисенә ярдәм итәргә тырышуы, үгез җигеп, урманга утынга, терлеккә печәнгә баруларын әле дә оныта алмый ул.

Гаиләдә тагын җиде бала үстәлә.

Гомер сәгатьләре вакытны алмаштырып кына торалар. Үсеп, Мөгаззәмә кул арасына керә башлый. Ул вакытта, колхозлар гөрләп эшләп торганда, яшьләргә шәһәргә китү катгый тыелган була. Авыл халкы алдына зур бурыч куела, хөкүмәтебез тарафыннан бишьеллык план бирелә: илебезне икмәк, ит, сөт-май белән тәэмин итәргә! Яшьләргә паспорт бирмәскә, авылда эшләп, производствоны күтәрергә кирәк!

Яшьлек еллары авыр чакка туры килгән, бала килеш ата назыннан мәхрүм булган Насыйх исемле чибәр егет авыл фермасына терлекче булып эшкә урнаша. Ә Мөгаззәмәгә килгәндә, гаиләдә сигез бала тәрбияләнгәнгә күрә, ул әти-әнисенә ярдәм итү теләге белән унөч яшендә хезмәт юлын фермада бозаулар караучы буларак башлап җибәрә.

Әйтергә кирәк, ул чорда бер бозау үлсә, аның өчен эшче кеше җавап тота. Аны шелтәләп кенә калмыйлар, үлгән бозаулар өчен түләүләр дә каралган була.

Биредә сынау срогын үткән, бераз тәҗрибә туплаган Мөгаззәмә озакламый сыер савучы булып урнаша. Авыл кешесе авыр хезмәткә карамый, эшләргә атлыгып кына тора бит.

Бераз алга китеп әйтәм: Насыйх ага, юл һәлакәтенә очрап, аягын имгәтсә дә, инвалид исемен үзләштерми, яңадан фермага әйләнеп кайта.

Аның бары бер сүзе җитә:

“Авыру булып яшәгәнче, хәләл икмәгемне эшләп алам”.

Ә өлкәнәйгән көннәрендә аңа “Ока” автомобиле бирелә. Аңа утырып, сөенә-сөенә мәчеткә гамәл кылырга йөри ул.

Ә Мөгаззәмә апа 43 ел гомерен яраткан сыерларына багышлый. Ул, алдынгы сыер савучы буларак, күпсанлы Рәхмәт хатлары, медальләр, орденнар белән бүләкләнә.

Авыр елларда көнне төнгә ялгап, авыр хезмәттә бил бөгеп, илебез икътисадын күтәрүгә зур өлеш керткән өчен “Хезмәт ветераны” исемен алып, лаеклы ялга чыга.

Ә хәзер яңадан аларның яшьлек елларына әйләнеп кайтып, мәңге онытылмас матур чакларны искә алыйк әле.

...Беркөнне яшь, матур кыз булып өлгергән Мөгаззәмә дуслары белән авыл клубына юнәлә.

Биредә үз урамнарында бергә уйнап үскән, бергә авыл фермасында хезмәт иткән Насыйх исемле баһадир гәүдәле егет белән үзара сөйләшеп китәләр.

Яшь егет Мөгаззәмәне өенә кадәр озатып куя. Ул кызга карата битараф булмаганлыгы, әллә кайчаннан бирле аны ошатып йөрүе турында әйтә.

Шуннан соң, очрашып йөри торгач, ике яшь йөрәк бер-береннән башка яши алмаслыгын аңлагач, өйләнешеп тә куялар.

Бераздан соң аларның беренче балалары Рузалия, аннан соң Фәнис, Рушания дөньяга аваз салалар.

Балаларына куанып, аларга карата зур җаваплылык хисе тоеп, яшь әти-әни тагын да тырышып эшлиләр, дәртләнеп тормыш алып баралар.

Әйтергә кирәк, Мөгаззәмә апа каенанасы Минҗиһан белән бик дус яшиләр. Бианасы аңа гел ярдәм итә. Ул оныкларын өзелеп ярата, аларны тәрбияләүдә көчен кызганмый.

Мөгаззәмә апа каенанасын бары тик яхшы сүзләр белән генә искә ала.

– Әнкәй бик әйбәт кеше иде. Кызганыч, якты дөньядан иртәрәк китеп барды шул. Урыны Җәннәттә булсын инде! – ди ул.

Насыйх ага белән Мөгаззәмә апаның бергә гомер итүләренә – 65 ел!

Әйтергә генә ансат, нәкъ бер кеше гомере бит бу!

Шушы вакыт эчендә язмыш аларны күпме борчу-мәшәкатьләр



Оныклары белән

белән сынаган! Ләкин Гарифуллиннар, бернигә дә бирешмичә, бер-берсенә терәк, кирәк булып, бары алга таба атлаганнар.

Насыйх абый белән Мөгаззәмә апаның олы кызлары Рузалия ире Рафаэль белән Татарстанның Яр Чаллы шәһәрендә гомер итәләр. Аларның кызлары Эльвира бухгалтер булып эшли, уллары Марсель – юрист.

Уллары Фәнис хәләл җефете Инзилә белән ике бала үстергәннәр. Ленар һәм Диләрә - шәхси эшмәкәрләр.

Гарифуллиннарның төпчекләре Рушания ире Нурхәтим белән шулай ук ике бала тәрбияләгәннәр. Кызлары Гөлгенә “Бердәмлек” газетасында җаваплы сәркатиб булып эшли. Ә уллары Салават полициядә хезмәт итә, подполковник дәрәҗәсенә күтәрелгән ул. Төрле кайнар нокталарда барган бәрелешләрдә, махсус хәрби операциядә катнашкан.

Бүгенге көндә Гарифуллиннарның 11 туруны (правнуки) бар.

Тормышта гел шатлыклар гына булмый. Сөенечләр белән көенечләр бер-берсен алмаштырып кына торалар. Кызганычка, Насыйх ага белән Мөгаззәмә апаның уллары Фәнис белән кияүләре Нурхәтим һәм Хәмит якты дөньяда юк инде. Үзләренә бары тик хәер-дога гына барсын.

Ә бәйрәм тантанасына килгәндә, оныклары Гөлгенә, әби-бабасын хөрмәт итеп, истәлекле бәйрәм турында бик матур видеоязма әзерләгән. Аны караган саен карыйсы килеп тора.

Әңгәмәбез ахырында мин юбилярлардан:

– Пар канатлар булып озак яшәүнең сере нәрсәдә? – дип сорадым.

Алар:

– Бер-береңә юл куеп, киңәшләшеп, ярдәмләшеп, авырлыгын да, җиңелен дә бүлешеп, яратышып яшәүдә, – дип җавап бирделәр.

Аннан соң:

– Аллаһыга шөкер, балаларыбыз беркайчан да йөзебезгә кызыллык китермәделәр, һәрчак аларның ярдәмен тоеп яшибез.

Кызыбыз Рушаниянең авылда калуы бик әйбәт булды. Ул һәр көнне безгә килә, хәлебезне белә. Тәмле ризыклар пешереп сыйлый, безне үз өендә кунак итә.

Балаларыбызга һәм оныкларыбызга Аллаһының рәхмәте яусын, безне зурлап җыелыштылар, шундый матур бәйрәм ясадылар, барысы да исән-сау, бәхетле булсыннар иде, бала хәсрәте беркемгә дә кагылмасын, – дип тә өстәделәр.

Ә Рушания ханым сөекле әтиәниләре турында:

– Әти-әниебез безгә үрнәк булып торалар. Алар бездә асыл сыйфатлар тәрбияләделәр. Намуслы, гадел булырга, кешеләрне рәнҗетмәскә, хезмәтне яратырга өйрәттеләр.

Нурхәтимемне мәңгелеккә югалткач, әткәй үз куллары белән өр-яңа өй салып бирде. Ятим калган балаларымны тәрбияләштеләр.

Аларга барлык туганнарым, балаларыбыз һәм оныкларыбыз исеменнән олы рәхмәтләребезне җиткерәсем килә.

Аллаһы Тәгалә үзләренә ике дөнья бәхетен бирсен иде!

Менә язмам ахырына да килеп җитте.

*Тормыш – мизгел, бары мизгел,*
*Әлләниләр өмет итмә.*
*Ахыргача бергә булсак,*
*Минем өчен шул да җитә,*
*Бәхет өчен шул да җитә!*

Әйе, Насыйх ага белән Мөгаззәмә апаның бәхетенә карап сөенерлек.

Шушы күркәм кешеләргә алдагы көннәрдә дә пар канатлы булып, озак еллар яшәргә язсын иде!

# Нәселләре белән уңганнар!

*Миләүшә Газимова*

**Авылының асыл хатын-кызы**

Уңган-булган, эшчән, тырыш халык яшәгән авыллар гөрләп торалар, алга баралар, гел үсештә һәм аларның киләчәге дә якты. Похвистнево районында урнашкан Гали авылы нәкъ шундый уңышлы авыллардан санала. Биредә гомер итүче булдыклы, эшлекле, хезмәт сөючән кешеләр туган җирләренең данын еракларга тараталар. Монда күбесе зурдан-зур теплицаларда үстерелгән яшелчәләрен, үзләре асрап суйган мал-туарның хәләл итен сатып көн күрә. Гомумән, Галинең хатын-кызлары аш-суга уңган, ир-атлары исә оста куллы.

Бу авылның йөзен чагылдырып, саклап яшәүче шундый күркәм кешеләрнең берсе – 77 яшьлек Бәһрәмия Зәйнетдин кызы Латыйпова үзе дә булдыклы, өч кызын – Дания, Наилә, Алсуны да ул шундый ук уңган-булган итеп, эш белән тәрбияләп үстергән.

“Бәһрәмия ханым бер дә тик тормый. Ә аш-суга оста инде, исләрең китәр! Әлеге көндә дә гел пешеренә, тортларга кадәр ясый ул. Үзе дә бик тә уңган, чая, җитез, матур тормыш корган хатын, балаларын да тәртип-әдәпкә өйрәткән, үзләрендә хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән.

Күңеле дә киң Бәһрәмия ханымның, барысына да ярдәм итәргә тырыша, туганнарын, күршеләрен бик якын күрә”, – дигән сүзләр белән тасвирлыйлар авылдашлары язмам героен.

Бәһрәмия апага балачагыннан тормыш нужасын күреп үсәргә туры килгән. Гаиләдә алар алты бала булганнар.

– Инәкәй белән колхоз кырларына чөгендер алырга да йөрдем, Самарга күкәй сатарга да бара идем. Яшьтән авыр эшләр эшләргә туры килде инде, нишлисең бит. Аның каравы барысына да өйрәндек, хезмәттән беркайчан да курыкмадым, гомер буе тормыш дилбегәсен нык тотып яшәдем. Бик күп сынаулар аша үтәргә туры килсә дә, Аллаһыга мең шөкер, сынмадым-сыгылмадым, – дип сөйли милләттәшебез.

Әйе бит, чыннан да, Бәһрәмия апа кыенлыкларны күп күргән. Ире Мидхәт 37 яшендә дөнья куйгач, 36 яшьлек хатын өч кызын берүзе үстергән. Сәламәтлек ягыннан да күп авырлыклар кичергән, юл һәлакәте дә читләп узмаган аны. Һәм дә инде, әлбәттә, газиз балаларын аякка бастырыр, аларны кеше арасында ким-хур итмәс өчен күп һәм катлаулы хезмәт куярга туры килгән аңа.

Бәһрәмия апа җәйләрен колхозда чөгендердә эшләсә, кышларын Куйбышев баш киемнәре фабрикасының Галидәге филиалында тегү теккән.

– Фуражкалар, җиңсез күлмәкләр, буркалар җитештерә идек. Цехтан тыш, мин әле өемдә дә тегү белән шөгыльләндем. Салкыннарда машиналар, тракторлар “туңмасын” өчен аларның алларын капларга тышлыклар тектем. Бу авыр эшне башкарырга кызларым бик нык булышалар иде.

Аларны аякка бастырыр, олы тормыш юлына чыгарып җибәрер өчен тырышырга туры килде инде. Икешәр сыер асрадым, орлык суганы (Галидә аны чәмчүк дип атыйлар – авт. искәрмәсе) үстереп саттым. Автобуста, поезда Чиләбе өлкәсенең Златоуст, Южноуральск шәһәрләре, Башкортостанның Учалы, Белорецк шәһәрләре базарла-



Бәһрәмия ханым кызлары Дания, Наилә һәм Алсу белән

рына йөрдем. Ел саен 4 – 5шәр тонна чәмчүк була иде.

Ераклarga чыгып киткән чакларда балаларымны әти-әнием, туганнарым караштылар. Әле дә ярый, әткәй белән инәкәй янәшәдә генә яшиләр иде. Ирем вафат булганнан соң, бер ел дигәндә, әтием дә үлде. Әнием 89 яшендә якты дөнья белән хушлашты. Соңгы елларда аны үзем карадым.



Рәфыйк һәм Наилә Кыяметдиновлар

Кызганыч ки, алты баладан без Рәсимә сеңелем белән икәү генә калдык, калганнары гүр ияләре булдылар, – дип сөйли Бәһрәмия апа.

Акыллы, зыялы, тәртипле, җаваплы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, тырыш, эшчән кеше буларак, авылдашлары арасында хөрмәт һәм абруй казанган ул. Шуңа күрә 1967 елда аны район Советына депутат итеп сайлаганнар. Һәм өстенә нинди генә вазифа алмасын, милләттәшебез аны җиренә җиткереп, намус белән башкарган. Шуңа күрә Бәһрәмия апа бүгенге көндә дә Гали халкы арасында хөрмәтле, абруйлы, мактаулы ханым булып яши бирә.

Тәүфыйклы балалар тәрбияләгән ана буларак та аны үрнәккә куярлык.

– Наилә кызым миңа: “Әй, әнием, безне эшләтеп үстердең дә инде”, – ди. Шулай инде, авыл баласы кечкенәдән хезмәттә. Бигрәк тә аталары булмагач, тырышырга туры килде бәбкәйләремә. Эш кушкач, иренебрәк торсалар: “Эшләгәнегез минем өчен булса, өйрәнгәнегез – үзегез өчен, балакайларым”, – дия идем үзләренә. Гәрчә алар мине күз карашымнан ук аңлыйлар иде.

Әлхәмдүлилләһ, лаеклы кешеләр булып җитлектеләр, битемә кызыллык китермәделәр, гел ярдәм итеп торалар, кадерхөрмәттә яшәтәләр һәм үзләренә шундый тәрбия биргәнем өчен рәхмәтләрен белдерәләр. Аллаһыга шөкер, өч киявем – Рәшит, Рәфыйк, Равил дә уңганнар, бик әйбәтләр, рәхмәт яугыры, мине үз әниләредәй күрәләр, – ди Бәһрәмия апа.

Милләттәшебез – затлы нәсел дәвамчысы. Әтисе белән әнисе ягыннан әбиләре шундый уңган булганнар аның. Әткәсенең атасы кәсепчелек иткән. Ике бабасы да – муллалар.

– Сәлахетдин бабам писер (писарь) булган, авыл советында эшләгән. Писер Сәлахетдин дип йөрткәннәр аны.

Инәкәем Кәримә ягыннан барысы да диярлек оста тегүчеләр, хәтта шигырь язучылар да бар.

Камалетдин бабам миңа кечкенәдән догалар өйрәтте. Гомумән, дини мохиттә тәрбияләндем мин. Аллаһыга шөкер, намазларны калдырмыйм.

Үз гомеремә бик күп авырлыклар кичерергә туры килсә дә, Аллаһы Тәгалә биргәненә канәгать булып, бәхет тоеп, исән-сау булуыма, туган һәр көнгә, бала-оныкларыма куанып, Раббыбызга барысы өчен дә шөкерана кылып яшим, – дип тәмамлады сүзен Бәһрәмия ханым.

Милләттәшебезнең кызлары һәм кияүләре – Дания белән Рәшит Латыйповлар, Наилә һәм Рәфыйк Кыяметдиновлар, Алсу белән Равил Сафиуллиннар менә инде бик күп еллар кәсепчелек белән шөгыльләнәләр.

## “Җимеш бәлешләрен әнием өйрәткәнчә пешерәм”

Наилә һәм Рәфыйк Кыяметдиновлар баштагы мәлләрдә яшелчә, ит сатканнар. Помидор, кыяр үстерер өчен – зур теплицалары, күпләп мал асрар өчен зур абзарлары булган. Ә сигез ел элек алар Галидә кулинария ачып җибәргәннәр.

– Баштан район кулланучылар җәмгыяте (райпо) авылыбыз универсамының бер почмагын арендага биргән иде. Шунда кулинария ачып эшли башладык, – дип сөйләп китте Наилә ханым. – Ә өч ел элек безгә әлеге бинаны сатып алырга тәкъдим иттеләр. Бер бүлегендә ирем хуҗалык кирәк-яраклары сата, икенче бүлегендә кулинария эшли. Ә бер бүлмәне арендага бирдем, анда Вайлдберриз пункты урнашты, халыкка товарларны үзем биреп җибәрәм.

Әнисенә охшап, аш-суга оста булган Наилә апа элгәре мәктәп укучылары өчен өендә камыр ризыклары пешерә торган булган, чөнки шимбәдә балалар укыган, ә ашханә бу көнне эшләмәгән. Соңрак инде аның кулинария ачу идеясе барлыкка килгән. Хәзер



Наилә ханым үзенең ышанычлы хезмәткәрләре белән


Рәфыйк, Наилә Кыяметдиновлар, аларның кызлары, кияве


Равил һәм Алсу Сафиуллиннар

хуҗабикәнең тәмледән-тәмле өчпочмакларын, бәрәңге пәрәмәчләрен, венгерча эремчек шәңгәләрен һәм яңа суйган иттән ясалган пилмән, мантый кебек ярымфабрикатларын авылдашлары гына түгел, ә район үзәгендә, тирә-як авылларда яшәүчеләр дә бик теләп сатып алалар. Бәйрәм табыннары оештыручылар, дини мәҗлесләр уздыручылар җиләк-җимеш һәм ит бәлешләренә заказ бирәләр. Вак бәлешне дә бик яраталар икән. Камыр ризыкларыннан тыш, бавыр кәтлитләре, тавык пешереп, салат ясап бирергә дә сорыйлар ди. Әйе, профессиональ дәрәҗәдәге оста әзерләгән ашамлыкларның тәме дә, сыйфаты да башка була бит ул!

Сыйфат дигәннән, кулинариядә ак май, югары сортлы он, куе сөт, хәләл ит кенә кулланалар, шуңа күрә монда җитештерелгән ризыкларны халык бик теләп ала, яратып ашый һәм аларны яңадан килеп ала.

– Җимеш бәлешләрен әнием өйрәткәнчә пешерәм, шуңа күрә алар бик тәмле килеп чыгалар да. Инәкәебез аш-суга бик тә оста бит безнең. Рәхмәт яусын, безгә дә кулинария серләрен өйрәтте.

Аннары, күңел җылыңны биреп пешерергә кирәк. Камыр кәефне сизә дигән сүз дә дөрес ул, – дип уртаклаша Наилә ханым.

Аның сүзләренчә, коллективта хөкем сөргән мохит та мөһим. Аның җитәкчелеге астында өч хатын-кыз эшли.

– Гөлнара, Гөлшат апа, Гөлназ шулхәтле әйбәтләр, рәхмәт яусын үзләренә, киңәшләшеп, рәхәтләнеп эшлибез. Алар булмаса, үзем генә бу күләмдәге мәшәкатьләрне башкарып чыга алмас идем, – дип шатланып сөйли ул.

Рульдә йөрүче Наилә ханым кирәк чакта заказларны кешеләрнең өйләренә илтеп тә бирә икән.

Әлбәттә инде, нинди генә уңган булсаң да, янәшәңдә ныклы терәк юк икән, тормышта зур уңышларга ирешүе авырга туры килер иде. Наилә ханымның янында шушындый ышанычлы таянычы – сөекле хәләл җефете Рәфыйк бар. Бергә гомер итүләренә 30 ел булган инде. Ике бала үстергәннәр алар. Ләйсәннәре Равил исемле акыллы егеткә кияүгә чыккан, алар Свердлау өлкәсендә яшиләр, уллары Әмиргә биш яшь тулган. Икенче кызлары Әлфия Самарда төзелеш көллиятендә белем ала.

– Өйләнешкәч, кечкенә өйгә килеп кердек, бернәрсәбез дә юк иде диярлек. Шулай, тырышыптырмашып, әкрен генә барысын да булдырдык, әлхәмдүлилләһ. Инәкәй дә, туганнар да бик булыштылар. Ирем өйне үз куллары белән салды, бар нәрсәне үзе эшли ул. Аллаһыга шөкер, хәзер бөтен әйберебез дә бар. Раббыбыз исәнлек-саулыктан аермасын.

Ике туганнарым – Мөдәррис абыем белән аның хатыны Рузалия апага, Расих абыема да бик рәхмәтлебез. Мәрхүм Расих абый өйләр салганда бик булышты. Мөдәррис абый белән Рузалия апа кулинария ачканда зур ярдәм күрсәттеләр, әле бүгенге көндә дә гел хуплап торалар. Шундый туганнар булуы – олы бәхет.

Гомумән, авылыбыз күркәм безнең, халкы миһербанлы, ярдәмчел, дус, бердәм. Шәһәрне беркайчан да яратмадым. Авыл җирендә шундый рәхәт ич!

Тормышымнан бик канәгать мин. Әнием исән-сау, туганнарыбыз белән гөр килеп яшибез, ирем әйбәт, балаларыбыз урнашкан, эшләребез уң бара. Раббыбыз киләчәктә дә Үз ярдәменнән ташламасын, – дип Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укый Наилә Кыяметдинова.

Киләчәккә планнары белән дә уртаклашты ул:

– Эшне тагын да яхшырту турында гел уйланып йөрим. Алга таба, Аллаһы насыйп итсә, менюны киңәйтеп, салатлар ясарга, икенче ашлар пешерергә дә исәп бар. Һәрхәлдә, киләчәктә дә халык күңеленә ятарлык, яхшы сыйфатлы, тәмле ризыклар җитештерергә ниятлибез.

### “Сәләттән тыш, теләк һәм тырышлык булуы мөһим”

Алсу һәм Равил Сафиуллиннар менә инде бик күп еллар ит саталар.

25 ел буена Әлмәт шәһәре базарларына йөргәннәр алар. Күп итеп сыерлар, атлар, үгезләр асраганнар. Галидән дә, башка авыллардан да маллар алганнар, һәм Равил әфәнде аларны үзе суя торган булган. Ә сигез ел элек туган авылларында йорт сатып алып, кибет ачканнар.

– Әлхәмдүлилләһ, юл газапларыннан котылдык, беркайда да йөрмибез, үзебездә генә сатабыз. Терлекне дә алай күп итеп асрамыйбыз хәзер. Авылыбыз кешеләренә Аллаһының рәхмәте яусын – малны үстереп торалар, безгә башлата да саталар, итләтә

дә тапшыралар, – дип сөенечен белдерә Алсу ханым.

Аларның кибетенә ит алырга авылдашлары гына түгел, Похвистневодан да, Богырысланнан да киләләр. Хәтта Самардан, Казаннан, Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан кунакка кайтучы кешеләр да алып китәләр. Яңа суйган, хәләл итләрен телеңне йотарлык, дип мактап, хуҗаларга рәхмәтләрен белдерәләр.

Уңган-булган Сафиуллиннар шулай ук үзләре җитештергән пилмән, мантый, тулма (голубцы), колбаса, казылык, тутырмалар да саталар бит әле. Ышанычлы ярдәмчеләре дә бар аларның – Рәдифә, Раилә ханымнар, Татьяна хезмәтләрен яратып, җиренә җиткереп башкаралар. Кибеттә сатучы булып Равил әфәнденең апасы, ачык йөзле, татлы сүзле Рузалия ханым эшли.

**– Эшкуарлык хезмәтен һәркем булдыра алмый бит. Моңа сәләт сезнең гаиләгезгә кайдан килде икән?** – дип кызыксындым Алсу ападан.

– Нәселдән килгән сәләттер инде бу. Әтием ягыннан Латыйповлар гомер буе кәсеп иткәннәр. Әткәем дә, аның абыйсы Мөҗәһит тә шушы эш белән шөгыльләнгәннәр. Ике туганнарым - Мөҗәһит абыйның малайлары да - эшмәкәрләр. Кызганыч ки, Расих абыем якты дөньядан бик иртә китеп барды шул. Мөдәррис абыем Похвистневода ит эшкәртү предприятиесен җитәкли.

Мөҗәһит абый да, Мөдәррис, Расих абыйларым да безгә бик күп ярдәм иттеләр. Аларга үз гомеребезгә рәхмәтле булачакбыз.

Аннары, шуны да әйтеп үтәсем килә – берәр нинди эш, шул ук кәсепчелек белән шөгыльләнер өчен сәләт кенә җитәрлек түгел, минемчә, теләк һәм тырышлык булуы да бик мөһим. Гомумән, безнең Гали авылы халкы бик уңган, хезмәт сөючән бит. Теплицаларда яшелчә үстерәләр, маллар суялар да продукцияләрен шунда ук сатып та кайталар. Бер-берсенә карап эшлиләр, ялкауланып ятмыйлар, тырышып-тырмашып дөнья көтәләр, – дип җавап бирде әңгәмәдәшем.

Сөбханаллаһ, Сафиуллиннарның эшләре уңышлы бара, тормышлары гөрләп тора. Алсу ханым белән Равил әфәнде 31 ел бергә гомер итәләр. Яшьтән дуслашып йөргәннәр алар. 20 яшьлек егет армиядән кайткач та, өйләнешкәннәр. Алсу ханымга әле 18 яшь кенә булган. “Без Равил белән 31 ел гына түгел, әйтерсең лә гомер буе бергә инде. Аның белән бәхетле булып яшим, Аллаһыга шөкер”, – дип елмая ул.



Равил әфәнде һәм Алсу ханым уллары Рафаэль, Расих һәм киленнәре Фәридә белән

Ике бала тәрбияләп үстергәннәр алар. Олы уллары Рафаэль, әти-әнисе эзеннән китеп, кәсепчелек белән шөгыльләнә. Шәһәрдә институт тәмамлагач, заводка эшкә урнашкан ул. Әмма күңеле газиз туган авылына тарткан, һәм егет, Галигә кайтып, биредә йорт алган. Күп итеп терлек асраучы Рафаэль Похвистнево мәчетендә кибет ачкан да анда ит, үзе җитештергән колбаса-казылыклар сата. Хатыны Фәридә, бер яшьлек кызы Мәдинә белән матур тормыш алып баралар.

Сафиуллиннарның икенче уллары Расих Самарда политехника техникумында белем ала.

– Сөекле инәкәем белән төп йортта яшибез. Равилнең әти-әнисе дә бездән ерак түгел генә торалар. Алар янына көн саен барып йөрибез, хәлләрен белеп, булышып кайтабыз. Каенатам белән каенанам бик әйбәтләр, мөнәсәбәтләребез яхшы безнең, беркайчан да сүзгә килгәнебез булмады.

Әлмәткә йөргән чакларыбызда балаларыбызны минем инәкәй һәм биатам белән бианам карадылар. Үзләренә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын. Раббыбыз киләчәктә дә шулай бергәләшеп, хәерле тормышта гомер итәргә насыйп итсен, – дип тәмамлады сүзен Алсу ханым.

Язмам геройлары турында аларның авылдашы, җирле “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Кәүсәрия ханым Шәйхетдинова түбәндәге фикерләре белән уртаклашты:

“Бәһрәмия апа да, аның кызлары, кияүләре дә – авылыбызның күркәм, һәрьяклап тәртипле шәхесләре. Бик тә тырыш, хезмәт сөючән, эшлекле, булдыклы кешеләр, аларның күңелләре дә саф, калебләре да пакь.

Аллаһы Тәгалә бу бәндәләргә миһербанлык, ярдәмчеллек, кешелеклелек кебек сыйфатларны мул итеп биргән. Галидә нинди генә чаралар, бәйрәмнәр, мәҗлесләр узмасын, Рәфыйк белән Наилә, Равил белән Алсу иң беренчеләрдән булып акчалата да булышалар, хәләл ризыкларыннан да өлеш чыгаралар. Махсус хәрби операция зонасына да гел ярдәм җибәреп, мәчет-мәдрәсәләргә дә сәдакаларын биреп торалар алар.

Авылыбыз хатын-кызлары Наиләнең кулинариясенә үзләре әзерләгән ризыкларны сатуга куялар. Кемдер бавырсак пешереп, кемдер торт ясап, кемдер токмач кисеп китерә. Шул рәвешле уңган-бикәләребез үзләренә аз гына булса да акча эшлиләр.

Авылыбызның асыл хатын-кызы, лаеклы балалар тәрбияләгән Бәһрәмия апа – кызлары белән дә, кияүләре белән дә горурлана ала торган Ана. Нәселләре белән уңганнар алар. Киләчәктә дә бу зур, тату гаиләгә бәхетле тормышларда авылыбыз күрке булып яшәргә язсын!”

*Летом 2022 года делегаты VIII съезда ВКТ, разбившись на секции, обсуждали в ходе дискуссии главный вопрос – кто и как выведет татар на новый путь развития. Перебрав многие фамилии, ораторы с огорчением отметили, что народ не ценит людей, внесших вклад в становление нации. Так, один из модераторов секции «Исторические личности и современные государственные деятели татар в аспекте формирования национальной гордости» директор Института татарской энциклопедии и регионоведения АН Татарстана И. Гилязов спросил у собравшихся, знает ли кто-то Н. Алимова (первый абсолютный чемпион Москвы по боксу в царской России), И. Ахмерова (руководитель советской резидентуры в США), И. Ислямова (исследователь Арктики, поднявший российский флаг над Землей Франца-Иосифа) или Г. Тазиева (бельгийский и французский вулканолог).*

*Зал промолчал. Не подали голоса, видимо, поскромничав, и посланцы самарской земли, хотя они могли прочитать публикации о первой тройке названных Гилязовым соплеменников в 18-м, 17-м и 21-м номерах журнала «Самарские татары». Лишь статьи о Тазиеве не было в нем. Устраняем сей пробел.*

*Рашид Шакиров*

# ГЕФЕСТА-КУЗНЕЦА ПОНЯТЬ ПЫТАЛСЯ



Итак, Гарун Сабирович Тазиев – инженер, спортсмен, исследователь, один из пионеров изучения вулканов, автор многочисленных интереснейших книг и фильмов об этих огнедышащих жерлах, основатель организаций вулканологов. Во второй половине минувшего столетия этому популярному ученому удалось донести свою страсть к вулканам до широкой публики. Выдающийся французский биолог, историк науки и философ Жан Ростан, чья деятельность была отмечена международными премиями, называл нашего соплеменника и россиянина по происхождению «рыцарем XX века».

Да, это был его век. Гарун появился на свет 11 мая 1914 года в городе Варшаве, который к тому времени уже почти сто лет находился вместе с Царством Польским в составе Российской империи и являлся административным центром ее Варшавской губернии. Отцом мальчика стал Сабир Тазиев, родившийся в Ташкенте (по другим источникам – в Самарканде) и происходивший из старинного княжеского татарского рода Дашкиных, корни которого уходят в Золотую Орду.

Дедом Сабира был Сайфетдин Дашкин, который, решив уклониться от службы в царской армии, вместе с братом переехал из села Дашкино Краснослободского уезда Пензенской губернии в Среднюю Азию. У его сына Таджедина Сайфетдинова в браке с Газизой из Казанской губернии появился наследник Сабир Таджиев. Таким образом, знаменитый вулканолог Гарун Тазиев, фамилию которого «офранцузили» (тат. – Һарун Таҗиев, фр. – Haroun Tazieff), – это правнук Сайфетдина Дашкина.

А мамой нашего героя стала уроженка г. Двинска (ныне – Даугавпилс в Латвии) Женитта Ициковна Клупт, имевшая отцом врача-еврея и православную мать Софи Арианов. Хотя не исключено, что в Женитте текла и татарская кровь. Во-первых, в соответствии с бельгийскими документами, ее



Родители Г. Тазиева

отца звали Ильяс, а, по информации сына Г. Тазиева, ее сестру – Асия, а тетю (сестру Ильяса) – Лола. Во-вторых, литератор русского зарубежья княжна З. А. Шаховская называла Женитту в своих воспоминаниях «российской татаркой».

Каким-то образом Шайхутдину абый, Шамседжихан апа и их четырем деткам (тогда их было столько) удалось выжить весной-летом 1944 года, когда жителей многих сельских регионов области вовсю «косила» септическая ангина. По информации, обнародованной краеведом Ш. Х. Галимовым, Новобуянский район стал своего рода эпицентром нежданного бедствия, а Ново-Урайкино называлось одним из самых проблемных населенных пунктов по заболеваемости ей. В этой деревне от эпидемии умерли 28 детей в возрасте до 16 лет, а данные о кончине взрослых – еще больше. Возможно, Шакуровым надо сказать спасибо молоку, которое на ранней стадии заболевания в определенной степени и помогало, и спасало. Ведь еще до рождения героя нашей статьи его отец имел в своем хозяйстве две головы крупного рогатого скота и одну козу.

Видимо, именно в этот военно-ангинный год Шамсутдин пошел в школу. По рассказам однокласс-



В школьный период, 1950–51 гг. Ш. Шакуров – 3-й слева в верхнем ряду



Ф. Шакурова – учитель Черновской школы

ников, он был очень старательным учеником. Начальное образование паренек получил в родной деревне, пятый класс окончил в Мулловке (тоже на татарском языке), а 6–7-й классы – в Сухих Авралях, где преподавали на русском. Понятно, что в последней школе подростку было очень трудно осваивать знания из-за невладения «великим и могучим». Затем он учился в Узюковском ПТУ Ставропольского района на тракториста, после чего работал на малой родине механизатором. С 1954 по 1957 год парень провел рядовым Советской Армии, служа в одном из куйбышевских стройбатов, в котором освоил специальность строителя.

Вернувшись домой, снова сел за руль колхозного трактора и в 23 года уже имел семилетний стаж работы в хозяйстве. А после трудовой деятельности на «железном коне» в совхозе им. Максима Горького (1960–1962 гг.) поступил в Рождественский сельхозтехникум, расположенный в с. Рождествено Волжского района. Успешную учебу Шамсутдин сочетал здесь с занятиями спортом (играл в волейбол) и общественными деяниями. Учащиеся доверили ему пост председателя профсоюзного комитета техникума, и он с присущей ему основательностью взялся за дело. В то время в стране возникли проблемы с некоторыми продуктами питания, и поэтому Шакуров организовывал бесплатные обеды для «грызущих гранит аграрных наук».

Одним из первых новоурайкинцев он окончил этот техникум в начале 1967 года и, получив специальность агронома, вскоре был назначен бригадиром тракторно-животноводческой бригады колхоза им. Ленина Волжского района. Но уже ближайшим летом данное хозяйство было передано совхозу «Юбилейный» того же района, и в нем наш дипломированный выпускник через три месяца стал агрономом отделения № 2.

А под конец года случилось знаковое событие в его жизни. В ноябре Шамсутдин попал на свадьбу земляка в Ново-Урайкино и там впервые увидел учительницу Фанию, которая после окончания вуза преподавала физику и математику в Мулловской средней школе. Новоявленному агроному девушка приглянулась, но та не обратила на него никакого внимания. Наш герой после этого почти каждый день начал приезжать на лошади к сестре, жившей в Мулловке. Точнее – якобы к сестре.

Однако Фания не видела его в упор, да и дел у нее было невпроворот: добавились уроки в открывшейся вечерней школе для сельской молодежи. К тому же в средней школе ее назначили старшей пионервожатой, а в колхозе выбрали секретарем комсомольской организации. Поэтому все ее дни были плотно заполнены уроками и подготовкой к ним, а также разными мероприятиями для школьников и работающей молодежи.

Тем не менее парень проявлял настойчивость, приезжая в любую погоду – хоть снег, хоть мороз. И однажды его родная сестра организовала встречу двух молодых людей, после которой Фания через три дня дала согласие стать женой этого целеустремленного Шамсутдина. Свадьбу сыграли спустя два месяца – 24 марта 1968 года.

Далее дадим слово самой Фании ханум: «Муж уехал на работу в совхоз «Юбилейный», а я продолжала вести занятия и дела в своей школе. После окончания учебного года приехала в совхоз «Юбилейный» и потом обратилась в Волжский районный отдел народного образования по поводу трудоустройства. Дело в том, что свободной ставки в «Юбилейном» не было, зато в соседней средней школе совхоза «Черновский» требовался учитель математики. Туда

я устроилась и проработала на одном месте 38 лет».

Теперь читателю становится понятно, почему Шамсутдин в июле 1968 года покинул «Юбилейный» и перешел на работу бригадиром-овощеводом отделения № 4 совхоза «Черновский». Как и супруга, он надолго осел здесь, возглавив в начале 1971 года только что созданное тепличное отделение № 6, о постановке дела им в котором мы уже поведали.

Совместную жизнь молодожены начали в общежитии п. Черновский, затем получили однокомнатную квартиру без удобств. Так пролетели 10 лет, которые пополнили семью двумя сыновьями – Илфатом и Ильгамом. Затем Шакуровы взялись за строительство дома по проекту героя статьи. В нем родился еще один сынок – Ильдар, так как супруги планировали иметь трех наследников.

Воспитывали они сыновей не словами, а личным примером трудолюбия на рабочем месте и в домашних условиях. Верно ведь сказано, что семья – это место, где принципы оттачиваются на наковальне повседневной жизни. Читатель уже получил представление о том, насколько эффективно трудился управляющий тепличным отделением. Об этом знали и его дети – как от земляков, так и благодаря своим наблюдениям. Ведь Шамсутдин ага нередко был вынужден привозить их на служебном мотоцикле «Восход» в теплицы, где мальчиков тепло встречали работницы: «Шакурята приехали!»

А педагогическая деятельность мамы прошла на их глазах. Фания ханум (в школе она была Фаиной Сулеймановной) любила свой предмет и умела так доходчиво и интересно его преподносить, что влюбляла учеников в математику, а попутно и в себя. Впрочем, эта любовь была взаимной, позволявшей отличнику народного просвещения РСФСР находить общий язык со школьниками, понимать их и вести разговоры по душам,




С женой на праздничном вечере по итогам года, 1978 год

а при необходимости делать тактичные замечания. От учеников-последователей по профессии она получала стихи. Вот одна из строф: «Как много в жизни значит самый лучший педагог! / Вы были с нами так добры, так терпеливы. / Хотя порой Ваш голос был и строг, / Но знали мы, что это справедливо».

Шакуровы, привыкшие содержать в порядке двор и дом, неустанно этим занимались, вовлекая в посильный труд и своих деток. Их отец, вставая ежедневно в пятом часу утра, кормил скотину, убирал за ней и не забывал про физзарядку. Дел во дворе хватало и после возвращения с совхозных теплиц. Порой семья держала до семи голов КРС, овец, кур, кроликов и козу, привлекавшую внимание соседских детей. Сыновья же нарезали для коров свеклу или другие овощи в корм, поили и кормили животных, ухаживали за ними, вычищали двор. Гости обычно удивлялись: «А вы даже в сарае полы моете?»

Ильгам разводил кроликов и кур породы Брама. Их петухи, как собаки, охраняли двор Шакуровых. Кроликами занимался и Ильдар, которому еще запомнились собственные действия на клочке земли придомового участка под названием «мой сад и огород». Там росли яблоня и куст смородины. На огородной части самый младший сын сначала занимался только поливом, а с возрастом начал выбирать, что посадить в землю, и от редисок перешел к томатам, перцам и баклажанам. А Илфат вспоминает сенокосы, эксперименты с выращиванием разных растений на даче в Подлесном, высадку до 30 соток картофеля и бахчи, работу в личной теплице.

Все цвело и благоухало и в саду этой семьи. Ее глава и сыновья сажали яблони и вишни, сливы и облепиху, другие деревья и кустарники, потом ухаживая за ними, проводя обрезку и формировку. Ну и конечно вокруг жилища было много цветов – главное хобби Ш. Шакурова. А внутри дома ребята помогали маме стирать, готовить, печь хлеб и выполнять иные работы. Соседи поэтому называли порой Фанию апа мачехой.

Знаменитый религиозный философ Р. Нибур полагал, что семейную жизнь невозможно сохранить духом справедливости. Скорее она, считал американец, поддерживается духом любви, который выходит за рамки справедливости. С последними словами его мнения мож-



Жена Ш. Шакурова с сыновьями, снохами и внуками, 2023 год



За ужином со своими родителями, женой и сыном, 1986 год

но поспорить, поскольку любовь, выходящая за рамки справедливости, способна творить любимчиков и вносить ненужное напряжение в семью. Но за важность наличия духа любви в ячейке общества голосуем двумя руками.

И этот дух не только витал в семье Шакуровых, а был в ней прописан. Подтвердим это словами Фании ханум про мужа: «Каким отцом он был! Любил детей безумно, от всей души. Зимой около дома, вырастала снежная горка – сам на тракторе возил снег. На каникулах меня с ребятами доставлял в Мулловку на месяц-полтора. Когда поспевала клубника, он приезжал собирать ее, заражая своим энтузиазмом мальчишек. Если в теплое время года выпадало свободное время, то на тракторе вез нас на природу – к озерам или реке Самарке, где мы купались часами, рыбачили и варили уху, гоняли чай из шиповника – готовил сам из корней, и играли с сынками. Мы очень старались показать им г. Куйбышев – посещали цирк, военные парады, а также татарские концерты, которые он очень любил». Из заграничных поездок Шамсутдин ага привозил домочадцам подарки, а жене помимо этого любил дарить букеты полевых ромашек и маков, роз и любимых ею тюльпанов.

В его доме было принято радоваться гостям и заботиться о родных и близких людях, особенно преклонного возраста. «Пусть к нам приходят гости, а не беды», – говорили супруги Шакуровы. Летом они, как правило, принимали своих племянников, часто приезжали в любое время друзья и родственники, по два зимних месяца жили родители. А племянница Фании апа по имени Фирдаус обитала у них два года пока училась в 9–10-м классах. «Когда наши бабушки и дедушки постарели, – вспоминают дети героя статьи, – они переехали к нам на постоянное жительство. Ели за одним столом, ни одного грубого слова со стороны родителей в их сторону мы никогда не слышали. Оба деда покинули этот мир у нас в доме, прожив 4–6 лет».

Шамсутдин абый не терял связь с малой родиной, стараясь помогать и всей родне, и землякам, обратившимся к нему с просьбой. Всегда помнил о родной сестре, которая рано осталась без мужа, и вместе с Илфатом и Ильгамом ездил заготавливать для нужд ее хозяйства солому и дрова на зиму. А детей преждевременно ушедших из жизни сестры и брата опекал до своих последних дней. Кроме этого, в течение пяти лет Шакуровы ухаживали за бывшей учительницей и внештатным корреспондентом районной газеты «Волжская новь» Р. А. Буровой, у которой не было детей, и она сама попросила о помощи. Все эти милосердные дела наших героев оставили отпечаток в мировоззрении их сыновей

Переняли сынки от родителей и тягу к чтению и знаниям. Дома к их услугам имелась неплохая библиотека и периодика, в том числе и на родном языке. Посещение общеобразовательной школы они совмещали с занятиями в другой школе – музыкальной. Илфат играл на аккордеоне, Ильгам – на балалайке и ложках, Ильдару же была куплена гармошка.

Старший сын окончил среднюю школу с серебряной медалью, а Ильгам и Ильдар учились на «4» и «5». Потом все трое получили высшее образование в сельхозвузе, действующем в пгт. Усть-Кинельский, причем Илфат и Ильдар стали обладателями красных дипломов, а позже защитили диссертации на соискание ученой степени кандидата сельскохозяйственных наук (первый сын) и биологических наук (третий сын).

Удивительно и то, что, проживая многие десятилетия не в татарском населенном пункте, Шакуровы не «растворились» в русскоязычной среде. Они не только общались дома на родном языке. но и отмечали мусульманские праздники и проводили обрядовые мероприятия даже тогда, когда это не приветствовалось властями. Инициатива исходила от Фании апа, которая приглашала соплеменниц на званые обеды и ненавязчиво вовлекала их в процессы соблюдения постов и исполнения намазов. Звучали в их доме и татарские песни.

И муж, и дети были приучены хозяйкой дома к блюдам татарской кухни, которые она умела отменно готовить и красиво подавать. Поэтому супруг на обед приезжал всегда домой. Жители поселка говорили, что по нему можно проверять часы. Если управляющий на мотороллере двигался к дому, значит уже 12.00. А когда видели его, едущего от дома на велосипеде, понимали, что время подходит к 14.00. Средство передвижения при этом менялось из соображений предоставления физической нагрузки организму после приема вкусной пищи.

Татарская культура нашла отражение в быту членов этой семьи: в убранстве дома, одежде и утвари. Самыми первыми среди односельчан они поставили антенну ТНВ, и начали смотреть передачи из Казани. Пятерка черновских Шакуровых всегда старалась присутствовать на сабантуях и мусульманских праздниках в родных деревнях Шамсутдина эфенди и Фании ханум – Ново-Урайкино и Мулловка. Глава семьи находил возможность договориться с начальством о предоставлении ему такой возможности.

Выйдя в 1996 голу на пенсию по инвалидности (донимало головокружение), он активизировал свою протатарскую деятельность. Благодаря его усилиям и движению людей в п. Черновский была создана мусульманская община, зарегистрированная в минюсте, и открылся молельный дом. Шамсутдин абый и сам начал совершать намаз, а также читать выученные молитвы на званых обедах единоверцев в поселке. Он помогал односельчанам при похоронах знакомых мусульман, используя для этого свои инструменты. А поскольку ближайшее к п. Черновский татарское кладбище находилось в поселке Нур, герой статьи инициировал приведение его в порядок. Было восстановлено ограждение этого места упокоения единоверцев, изготовлены и приобретены обрядовые ритуальные принадлежности, для хранения которых Ш. Шакуров вместе с А. Абзаловым соорудили из своего материала небольшой сарай.



Фания ханум приучает к намазу внучку Алию, 2006 год



Праздничный намаз в Ново-Урайкинской мечети, 2007 год. Ш.Шакуров – в центре 1-го ряда

Запомнился наш пенсионер жителям Черновского и своими делами на благо всего поселка. Он организовывал выпас скотины, а на своей улице добился, чтобы работала колонка с водой. Участвовал в работе общества инвалидов поселения Черновский, проводя различные мероприятия и поздравления ветеранов. Даже в 70 лет Шамсутдин Шайхутдинович был одним из активных членов этого общества, правой рукой председателя первички И. А. Михайлова. Последний вместе с начальником территориальной соцслужбы Р. А. Валитовой и председателем профкома ЗАО СП «Черновский» В. Я. Мельниковым пришел поздравить коллегу с юбилеем. Гости вручили и ценный подарок от директора хозяйства В. Е. Минеева.

Продолжал герой этой публикации заниматься и личным подворьем, которое в поселке признавалось как «Двор образцового содержания». Он женил Илфата и Ильгама, а когда со временем появились три внучки, любил с ними нянчиться. Да и не только нянчиться! Вот что отложилось в памяти старшей внучки Камили: «Все с ним было интересно! Уже будучи немолодым, всегда играл со мной в догонялки и прятки. Относился, как ко взрослой, давая интересные задания. Например, можно было законно залезть на крышу сарая и собрать яблоки или поваляться

и поиграть на сеновале. Никогда не ругал, только мог поправить. Всегда брал с собой в магазин, сажая на велосипед или мотороллер. Там мне можно было выбрать любой товар. Только абика потом нас ругала – опять скупили все на свете».

Всюду у Шамсутдина ага были знакомые дедушки и бабушки, которые приглашали его за стол, и он не отказывался от угощений. Кстати отметим, что этот гость не употреблял алкоголь и не курил, приучив и сыновей так же относиться к сей «заразе». По словам супруги, «в нем умещалось столько всего хорошего, что словами это не передать. Так, он не умел злиться и ругаться, хотя имел свою позицию и ни перед кем не склонял голову. От него веяло только положительной энергией. На вид строгий, а душа как у ребенка».

В общем, среди забот-хлопот умели в радости жить черновские Шакуровы, уделяя внимание друг другу. А, по мнению мудрых людей, такое внимание – ключ к гармонии в семье. Единственное, что расстраивало нашего героя на стыке веков, так это – развал СССР и начавшееся вскоре запустение его родного 6-го отделения. «Когда мы проезжали мимо заброшенных теплиц, на отца было тяжело смотреть, у него слезы наворачивались на глаза, – говорит сын Ильгам. – Стены, некогда полные жизни и плодородия, теперь осыпались, словно и они теряли надежду».

А затем возник еще один повод для расстройства Шакуровых – новое заболевание главы семьи. Он мужественно с ним боролся, не жалуясь на судьбу и не охая-ахая, а с улыбкой на лице, появлявшейся то от заботы близких, то от наблюдения за внучкой Алией, приехавшей из Самары.

24 октября 2008 года продолжительная болезнь довела Шамсутдина Шайхутдиновича до кончины и похорон в родном селе. Как очень светлому человеку, ему довелось умереть в пятницу. Проститься с Ш. Шакуровым пришло много людей, а последнюю молитву прочитал своему хорошему знакомому Вагиз хазрат Яруллин.

До сих пор в Черновском вспоминают этого земляка как настоящего руководителя и прекрасного человека, мечтая о появлении таких людей в большом количестве. Гордятся им и сыновья, поскольку отец являл собой пример достойного гражданина своей страны и был для них надежной опорой в правильной жизни, А супруга главного персонажа статьи говорит коротко: «Спасибо Аллаху, что такой муж встретился на пути». Жалеют родные. что не все внуки увидели своего бабая (их теперь 11, а еще есть и правнучка), что не успел он отдохнуть после годов тяжелой работы и быть рядом с женой и сыновьями при поездках к морю, а также в Египет или Турцию.


С внучками, 2007 год

Да, жизнь продолжается, но без Шамсутдина эфенди. По-прежнему заботится о своих потомках и близких Фания Сулеймановна, радуясь тому, что ее сыновья, их жены и дети соблюдают пост, владеют родным языком и интересуются татарской культурой. Глава команды внуков Камила так говорит о бабушке: «Абика – очень интересная женщина, любимая семьей, коллегами-учителями и учениками. Старается научить меня всему и до сих пор делится своим опытом».

Сыновья же, головы которых уже тронула седина, продолжают отцовскую аграрную линию. Илфат трудится в фирме по обеспечению сельхозтоваропроизводителей средствами защиты растений и проживает с семьей в п. Черновском, недалеко от мамы. Ильгам занимается поставкой семян, удобрений и средств защиты для сельского хозяйства, обитая с семьей в Самаре, но имея дачу в родном поселке. Он соответствует современному статусу многодетного отца – четыре дочки и два сына. А Ильдар, как и члены его семьи, стал жителем Подмосковья и работает в международной компании, занимаясь картофелем и побывав по производственной необходимости во многих городах России.

Всем трем потомкам Ш. Шакурова присущи аккуратность и порядочность, любовь к красоте и ответственность, перенятые от папы. Думается, что им передалось и крепкое шамсутдиновское рукопожатие. А успехами сыновья должны превосходить своих родителей, как ученики – учителей. Всякими успехами: трудовыми, общественными и, само-собой, татарско-семейными. Отметим с удовлетворением, что именно в этом направлении они и движутся.

Замечательно сказала однажды о ячейке общества мать Тереза: «Что вы можете сделать для укрепления мира? Идите домой и любите свою семью!» Прислушаемся же к совету основательницы союза «Миссионеры милосердия», действовавшего по данным 2012 года более чем в 130 странах, которая получила Нобелевскую премию мира 1979 года, а спустя 20 лет возглавила список самых уважаемых людей прошлого века согласно опросам Института Гэллапа. Любим семью, как это делают Шакуровы, и никаких гвоздей!

# “СУГЫШ ЕЛЛАРЫ - ТӨЗӘЛМӘС ЙӨРӘК ЯРАЛАРЫМ”

***«Сугыш балалары» дип аталган олы буын кешеләре кечкенәдән нужа күреп, ач-ялангач килеш үссәләр дә, алар тормышта киң күңелле, ачык йөзле шәхесләр булдылар һәм хезмәттә дан казанып, матур яшәделәр.***

***Фәрид Ширияздановx***



Иске Ярмәк авылында яшәүче Җәрия апа Зыятдинова – менә шуларның берсе. Ул әле 84 яшендә дә улы Ринатның кибетендә сатучы булып эшли. Авыр елларда күргәннәренә таянып, бәетләр чыгара, үзенең тирәндә яткан хисләрен шигырь юлларында чагылдыра.

«Тимпы» дип аталган ике тәгәрмәчле кечкенә кул арбасы белән тормышны тартып барган вакытлар аның күңелендә аеруча тирән эз калдырган. Ярмәк авылында ул арбаны «тимпы» дип атасалар, башка җирләрдә аны әле «Уфалла арбасы» дип тә атыйлар.

Әнисе ач килеш авыр эшләрдә эшләгәндә аның сөте булмый. Алабута ипиен чәйнәп, аны марляга төреп, имчәк баласына каптырганы турында яза милләттәшебез бер шигырендә. Үзе кичергән башка бихисап авырлыклар турында язган шигырьләре дә күп аның.

Әтисе Бөек Ватан сугышына киткәндә, ул ун көнлек сабый гына булып кала. Аны юксыну, сагыну хисләре һәм ачлык, ялангачлыктан интегеп яшәүләре дә аның иҗатында зур урын алып торалар.

Мәсәлән, сугыш тәмам булгач, хөкүмәт тарафыннан сугыш ятимнәренә нинди булса да кием-салым бирәләр. Аңа бер кофта эләгә. «Сары кофта» исемле шигырендә ул моңа башта чиксез куаныч кичерүе турында яза. Тик әнисе бу кофтаны онга алмаштыра һәм кайнар суга он бутый да боламык ясый. Шушы боламыкка күз яшьләрен агыза-агыза ашавын искә алганда әле хәзер дә күзләре яшьләнә. Күрәсең, тамагы ач булса да, кофтасыз калу аның өчен шулкадәр зур югалту була!




Мәктәптә 7 классны тәмамлагач, ул почтальон булып эшли башлый. Эш дәверендә ул һәр өйдә үз кешегә әверелә һәм олы хөрмәткә лаек булып яши. Ни дисәң дә, халык аның хәлен яхшы аңлый, ә ул – алар хәлен. Чөнки күпчелек өйләрдә әтиләре, абыйлары сугыш кырларында ятып калган яисә имгәнеп, чирләп кайткан кешеләр яши. Күп еллар сберкассада контролер булып эшли.

Каһәрле сугыш купләрнең йөрәгенә төзәлмәс яралар салса да, кешеләр бердәм булып, ярдәмләшеп, тормышны акрынлап җайга салганнар. «Сугыш балалары» дип аталган кешеләрнең күргәннәре һәм аларның шул елларда күрсәткән хезмәт батырлыклары турындагы хәлләрне уйлаганда, күп нәрсә гаҗәпләндерә. Бу хактагы әңгәмә барышында Җәрия апа төрле сорауларга түбәндәге җаваплары бирде.

***– Сугыш елларында халкыбыз кичергән авырлыкларны хәзер аңлап та, күз алдына китерептә булмый. Боларны искә алганда нинди хисләр кичерәсез?***

– Авыр еллар истәлеге күңелдә авыр йөк кебек. Аларны онытy һич тә мөмкин түгел, чөнки ул авырлыклар гел истә һәм төзәлмәс яралар булып күңелгә нык уелган. Мәсәлән, кышкы чатнама суыкларда тәрәзәләрне бармак калынлык карлы боз каплаган була. Шул бозны тын белән өреп эреткәч кенә, шул тишектән якты дөнья күренә.

Мичкә ягар өчен мин Юкәле Тау алдындагы Сок елгасы буеннан тал чыбыгы кисеп өеп куям, әнием аны кечкенә чанада ташый. Дөрес, ул чи тал чыбыгының җылысы да шулкадәр генә була иде.

Әни көне буе эшләсә дә, колхозда акча түләнми. Без аның түшенә яшереп алып кайткан бодаен куырып ашар өчен әнине көн буена көтеп утырабыз. Туң бодайдан күкрәгенә ничек салкын тимәгәндер – белмим. Кесәләрен, аяк балтырларын капшап тикшерсәләр дә, күкрәкләренә кагылмаганнар, күрәсең.




Үсә төшкәч, үзебез дә 7 - 8 яшьтән колхоз эшенә йөри башладык, аеруча утау эшләре безгә нык эләкте. Ә 12 - 13 яшьтә зурлар белән бертигез эшләү гадәти хәлгә әверелгән иде.

Иске Ярмәк тарихы турындагы китапта да сугыш елларындагы авырлыклар хакында күп язылган. Мәсәлән, анда авылдан 681 кеше сугышка китсә, шуларның 316сының яу кырларында ятып калуы билгеле. Якынча исәп белән дә, бу бит авылда 500ләп сугыш ятимнәре үскән дигән сүз! Әлбәттә, аларның күбесе, авырлыкларга чыдамыйча, вафат та булганнардыр. Тик безгә, исән калганнарга, сыйрат күпере аша узгандай, зур сынаулар аша үтәргә туры килде.

Ул авырлыклар турында күп сөйләргә була. Әлбәттә, хәзерге вакытта аларга ышану да кыен. Мәсәлән, ипине мин беренче тапкыр 16 яшемдә ашау бәхетенә ирештем. Ә аңа кадәр без бит ни туры килсә, шуны ашап үстек! Төрле үләннәр, тамырлар, черек бәрәңгеләр – берсе дә калмады.

Ә иң үкенечлесе – мин үз гомеремә авыз тутырып “әти” сүзен әйтергә тилмереп үстем. Авыл өстеннән берәр самолёт очып узса, мин: “Әтине кайтаралар!” – дип аның артыннан кычкырып чаба идем.

Тормышта һәркем үз тиңен эзли. Менә мин дә Тәлгать исемле, үзем кебек, ятим егет белән гаилә кордык һәм өч бала үстердек. Ни кызганыч, бер улыбыз, юл фаҗигасенә эләгеп, һәлак булды. Ирем белән матур яшәдек. Ул үз гомеренә фермада, малчылыкта эшләде. Кызганыч ки, гомере генә кыска булды. Ул 60 яшендә бу дөньядан китеп барды.

***– Сезнең буын кешеләренең күбесе, озын гомерле булып, матур яшәде. Кеше мөмкинлекләренең чигендә булган авырлыклар аша узсалар да, алар, ачык, шат йөзле, ярдәмчел һәм киң күңелле булып, үрнәкле гомер кичерделәр. Хәзер моны ничек аңлап була?***

– Авырлыклар кешеләрне берләштерә, бер-берсенә якынайта. Ул чакта мохтаҗ кешегә һәркем ничек тә үз ярдәмен күрсәтергә тырыша иде. Мәсәлән, күршегә бер кашык тоз сорап керүләр, шырпы булмаган чакларда мич кабызырга утлы күмер сорап күршегә керүләр, кечкенә савыт белән он сорап тору һәм башкалар гадәти хәл иде. Хәлләрне сорашып, кайгы-шатлыкларны уртаклашып яшәсәң, авырлыкларны җиңеп була.



Ул заманда мәктәптә дә, авыл җәмгыятендә дә коллективизм хисе нык тәрбияләнде. Шуңа да бәйрәмнәр ничек матур узса, өмәләр дә бәйрәм төсе ала иде. Элгәре бер-береңә ярдәм итеп яшәү дә зур изгелек саналды. Халык белән гел тыгыз элемтәдә булганга, без әле үзебез дә төрле чаралар оештыра идек. Мәсәлән, авылыбызның 250 еллык юбилеен үткәргәндә, без бәйрәмне театр рәвешендә үзебез матур һәм күңелле итеп оештырдык.

Безнең өебез Сок елгасы буенда булганга, язгы ташу вакытын да без зур бәйрәмгә әверелдерә идек. Әлбәттә, монда мәктәп укытучылары, колхоз җитәкчеләре, клуб һәм төрле оешмалар хезмәткәрләре дә актив катнаштылар. Самавыр куеп, төрле ризыклар алып килеп, күңел ача идек. Ул вакытны мин күчле бер рухи күтәрелеш чоры булган, дип саныйм. Нәтиҗәдә тора-бара авыл тормышы да югары үсеш юлына басты.

***– Авыр елларда күп кеше тик 4 - 5 класслы белем генә алуга ирешкән. Ә ул вакытта 10 классны тәмамлау хәзер югары белем алуга тиң булган. Ә сез ничек урта белем алуга ирештегез?***

– Белемгә омтылу минем әтием ягыннан да, әнием ягыннан да килгән. Безнең нәселдә укытучылар күп, прокурорлар, судьялар һәм башка зур кешеләр дә бар. Мәсәлән, ике туган абыем Дамир Бәдретдинов Казанда театр училищесы директоры һәм мәдәният министры урынбасары булып эшләде. Ул данлыклы «щепкинчылар» исемлегендә. Бертуган апам да Бөгелмәдәге «Учительский институт» тәмамлады һәм Денис авылында укытучы булып эшләде. Ике туган энем Әсфәндияр Вәлитов, авиация институтын тәмамлап, авиаконструктор булды.

Үземнең югары белем аласым килсә дә, әнием ялгызы гына каласы килмәде һәм мине беркайда да җибәрмәде.

***– Сез – бай тормыш тәҗрибәсе туплаган шәхес. Бу уңайдан үткәндәге, хәзерге хәлләр һәм киләчәк турында нинди уй-фикерләр белән яшисез?***

– Без тормышның кадерен белергә һәм андагы барлык авырлыкларны җиңәргә өйрәнеп үстек. Балачактагы авыр елларда безнең исән калуыбыз бер серле могҗиза булса, калган тормыш юлларын без үзебез ярып, аны җайга салу өчен бар куәткә тырышып эшләдек. Аллаһыга шөкер, моның нәтиҗәсен дә күрдек. Ул вакыт ачык йөзле, шат күңелле, уңган һәм эшкә батыр кешеләр заманы иде.

Монда мин бер нәрсәне ачык итеп әйтә алам: кеше тормышы – ул аның эчке дөньясының чагылышы. Җәмгыятьтә дә шундый ук хәл. Андагы кеше тәрбиясе нинди – җәмгыятьнең уңышлылыгы да менә шуңа бәйләнгән. Мәсәлән, элгәре хезмәткә, хезмәт кешесенә хөрмәт бар иде. Безнең буын халкы уңышлы зур эшләр башкарды. Нәтиҗәдә илебез көчле дәүләтләрнең берсенә әверелде. Космос киңлекләрен яулады.

Хәзер бар нәрсә дә үзгәрде. Булганның кадере бетте. Кешеләрдәге туганлык хисләре зәгыйфьләнде, хөсетлек артты һәм намуссызлык көчәйде. Ә иң мөһиме – хезмәткә хөрмәт бетте.

***– Татарлар, элгәредән гасырлар дәвамында нужа чигеп яшәсәләр дә, һәрвакытта тормышның җаен таба белгәннәр һәм үрнәкле гомер кичергәннәр. Ә хәзер гөрләп торган тормыш алып барган авыл югалу юлында. Моны ничек бәялисез?***

– Кешене әдәплелеккә, эш сөюгә кечкенәдән тәрбиялиләр. Нинди генә авырлыклар кичерсәләр дә, халыкны бердәмлек, үзара ярдәмләшү саклаган. Бу сыйфатлар татарларның канында, геннарында гасырлар буена сакланган.

Хәзер менә шулар зәгыйфьләнде. Халыкта үз авылына, туган җиренә карата хөрмәт бетте. Җәмгыятьнең җегәрлеге какшады. Бу – коточкыч зур фаҗига. Җирләре халык кулында сакланса, авыл кайчан булса да үсеш юлына басар дигән өмет бар. Шулай булмаганда, халык җирләрен читләргә сатып бетерсә – авыл юкка чыгачак, ахыр чиктә анда чит-ят халыклар яшәячәк дигән сүз. Аллаһыга шөкер, минем бер улым, Себердә эшләсә дә, авылда ике катлы йорт салды.

Икенче улым Ринат маллар асрый, алар өчен үзенә тиешле җирләрдә азык әзерли. Кибет тота һәм анда сөт, май, ит һәм башка төрле ризыклар халыкка тәкъдим итеlә.

Эшләгән, тырышкан кеше беркайчан да ким-хур булмый. Хәләл көч белән тапкан мал һәрвакытта бәрәкәт китерә. Хәрәкәттә – бәрәкәт, диләр. Мин әле үзем дә кулымнан ни килсә, шуны эшлим, тик тора алмыйм.



Әтисе Ризатдин фронтта һәлак була



Әнисе Факия

# Чиксез авырлыклар кичерсәләр дә, “сугъыш балалары” матур яшәделәр

*Һәр заманның, чорның үз тамгасы, үз билгесе бар. Сугыштан соңгы авырлыклар җиңелеп, тормыш җайлана башлаган вакытны алсаң - ул чор җәйге таңда офыктан яңа гына кояш чыгып килгән, рәхәт чакларны хәтерләтә.*

***Фәрид Шириязданов***

Шул вакытны сагынып искә алганда, тормышны бар куәткә алга, якты киләчәккә алып барырга тырышкан авыл халкы күз алдына килә. Болар – матур өметләр, якты хыяллар белән яшәүче “сугыш балалары”, корычтай нык токым кешеләре иде.

Ач, ялангач килеш, черек бәрәңге, алабута ашап, ялгыш кына үлем кочагыннан котылып калган булсалар да, алардагы ташып торган яшәү дәрте, киң күңеллелек, ярдәмчеллек, бердәмлек гаҗәеп бер күренеш иде.

Тормыш үргә атлаган чор ягымлы йөзле, киң күңелле һәм ашкынулы хисләре ташып торган кешеләр күплеге белән танылган, хыялый бер заман иде. Хәзер инде ул вакыт, матур бер төш кебек, сагындыра, сокландыра һәм уйландыра.

Гомумән, Иске Ярмәк авылы – һәрвакытта эшкә уңган, шаян сүзле, телгә оста һәм төрле яклап сәләтле халкы белән танылган атаклы төбәк. Бу уңайдан истәлекләргә бай, матур һәм бәрәкәтле заман кешеләрен искә алганда, һәрвакытта елмаючан Наил абый Шәрәфетдинов күз алдына килә.

Ачык йөзле, киң күңелле кешеләр белән аралашу һәрвакытта җанга рәхәтлек бирә, тормышка ямь өсти һәм хәсрәтле уйлардан арындыра. Алар янында дөнья яктырып киткәндәй була, һәм шунда туган матур хисләр дә озак саклаunion налар.

Ирле-хатынлы Наил абый һәм Гүзәл апа Шәрәфетдиновлар гаи-



ләсен алганда, менә шундый уйлар башка килә... Андый эчтәлекле гомер кичергән, бай табигатьле кешеләр – үз чорының өлгесе, матур бер билгесе. Аларның истәлеген, хезмәт һәм тормыш үрнәген саклап, киләчәк буыннарга җиткерү хәзерге хәтерсезлек, өметсезлек арткан һәм битарафлык өерелеп килгән заманда аеруча мөһим мәсьәлә булып тора.

Наил абый һәм Гүзәл апа Шәрәфетдиновларда “сугыш балаларына” һәм Иске Ярмәк авылы халкына хас булган матур сыйфатлар мул тупланган. Бигрәк тә алардагы уңганлык, хезмәт сөючәнлек һәм кешеләр белән уңай мөнәсәбәттә булулары аеруча сокландыра.

Ни кызганыч, хәзер хезмәт батырлыклары күрсәтеп яшәгән һәм бар булган тормыш авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәргән кешеләрнең күбесе инде бакыйлыкка күчте.

Түбәндә Наил абый һәм Гүзәл апа Шәрәфетдиновлар турында үзләре белән бергә эшләгән чордашлары, хезмәттәшләре, шулай ук балалары һәм оныклары якты истәлекләре белән уртаклашалар.



**Коминтерн исемендәге колхоз рәисе Дәүләтша улы Дәмил Хәсәншин:**

– Тормышта һөнәр ияләренә һәм оста куллы кешеләргә һәрвакытта хөрмәт аеруча зур булды. Халык андыйларны һәрвакытта “осталар” дип зурлады. Элгәре хезмәткә дан җырлау һәм хезмәт ияләрен төрлечә хөрмәтләү гадәте бар иде. Наил абый Шәрәфетдинов – менә шулар исәбендә.

Без үзебез дә алар үрнәгендә һәм хезмәткә хөрмәт булган чорда тәрбияләндек. Элгәре бар җирдә дә: “Хезмәткә дан!”, “Хөрмәт нигезе – хезмәт”, “Хезмәт кешене матурлый, зурлый һәм данлый”, “Хезмәтенә күрә хөрмәте!” кебек шигарьләр (лозунг) эленгән иде.



Наил туганы Гамил белән

Ул чактагы: «Мы рождены сказку сделать былью!» кебек җырлар тәэсирендә киләчәккә якты өметләр баглап үстек. Ә без хезмәткә керешкән вакыт авыр эшләр механизацияләнә башлаган һәм тормыш кискен күтәрелеш юлына баскан чорга туры килде. Ул нужа чигеп яшәгән халыкның матур тормыш турындагы хыялы чынга аша башлаган, бәхетле вакыт иде...

Техника һәм механизмнарның кешеләрне авыр кул эшләреннән азат итүе дә халыкка зур җиңеллек китерде. Колхозда акча да түләнә башлагач, тормыш та җайлана барды. Бу колхоз хуҗалыгының кискен күтәрелеш алган, искиткеч матур бер чор иде. Халыкның көнкүреше, авыл тормышы гел үсеш юлында булды. Әлбәттә, монда бөтен авыр эшләр техникага йөкләнгәч, төп җаваплылык механизаторларга һәм белгечләргә йөкләнде.

Уңыш өчен аяусыз көрәш барган чакта язгы чәчү һәм урып-җыю эшләре дә тәүлек дәвамында, туктамыйча барды.

Бу бәрәкәтле вакытны искә алганда, Наил абый Шәрәфетдинов кебек оста куллы хезмәт батырлары күз алдына килә. Ел әйләнәсендә ул колхозның мехмастерскоенда техника ремонтласа, урып-җыю вакытында комбайнда эшләде. Алар улы Фәнис белән елына 40ар мең центнерга кадәр ашлык суктыруга ирешәләр иде.

Нинди дә булса яңа техниканы көйләргә яисә механизация ысуллары кертергә кирәк булганда – һәркайда алар алыштыргысыз новаторлар һәм рационализаторлар буларак танылдылар. Гомумән, Наил абый һәрвакытта үз эшенә чын күңелдән, җаны-тәне белән бирелгән, уңган хезмәткәр булды һәм халык арасында хөрмәт, дан казанып яшәде.

Ул чакта халык та үзара ярышып, ашкынып эшләде. Колхозда пищекомбинат төзелде. Анда пешерелгән ипи әле башка авылларда, хәтта Кләүле район үзәгендә дә сатыла иде. Колхозда көнбагыш мае ясау, туңдырма, макарон, печенье һәм башка ризыклар эшләп чыгару, матраслар, кием-салым тегүләр булуы турында сөйләсәң, 40 - 45 яшьлек кешеләр, боларга ышанмыйча, бу истәлекләрне фантазиягә саныйлар.

Ә фермаларда сөтүткәргечләр корып, һәркөнне хөкүмәткә 10 - 15әр тонна сөт сатылуы турындагы сүзләрне бигрәк тә! Ул вакыттагы казанышлар турында бик күп мисаллар китерергә була. Андагы бар эшләр дә механизацияләнеп, колхозның һәм авылдагы халык көнкүрешенең үсеш вакыты хәзер әкияти бер күренеш кебек. Менә шуларны Наил абый Шәрәфетди-

новтай оста куллы, хезмәт сөючән кешеләр булдырды да инде, – диде Дәмил Хәсәншин.

**Гомәр абый Гайсин – малчылыктагы эшләрне механизацияләү буенча инженер:**

– Наил Шәрәфетдинов белән без – бер чор кешеләре – “сугыш балалары”. Безгә, әле сөякләребез дә ныгымаган унике-унөч яшьлек балаларга, иң авыр эшләрне кул белән башкарырга туры килде. Таркау, хәерче хәлдәге колхоз хуҗалыгын аякка бастыру өчен олылар белән бертигез итеп, үзебезне аямыйча эшләдек. Нәтиҗәдә безнең буын кешеләре авыл тормышында әкияттәй матур үзгәрешләр булдыруга ирештеләр.

Авылга техника кайта башлагач, тракторларга, комбайннарга, машиналарга утырып, көне-төне тырышып эшләдек. Нәтиҗәдә колхоз миллионлаган сум табыш алуга иреште. Авылда яшәү шәһәр көнкүрешенә тиңләште.

Бу чорны искә алганда, күп кенә эш осталары күз алдына килә. Бу исәптән Садршәһит улы Наил Шәрәфетдиновны телгә аласы килә. Аныңдай һөнәр ияләренә “осталар”, “алтын куллы кешеләр”, диләр. Әлбәттә, андыйларга халык һәрвакытта аеруча зур ихтирам күрсәтеп килгән. Чөнки кемнең нәрсәседер ватылса яисә көйсезләнсә – барысы да алар каршына килә.

Икенче яктан – алар уңай холыклы. Беркайчан да кешеләр белән оршышып-талашып йөрмәделәр. Алардагы гадәти булмаган тагын бер күренеш – ул буыннан-буынга бирелеп килгән комбайнчылар һәм күптөрле һөнәр осталары булуы.

Безнең Коминтерн исемендәге колхоз производствосы заманында кискен үсеш юлына басты. Алдынгы тәҗрибә кулланып, фән һәм техника яңалыкларын, алдынгы технологияләр кертеп, рационализаторлык эшләрен башкаруда да Наил Шәрәфетдинов һәрвакытта актив катнашты.



Уллары, килене белән

Авыл хуҗалыгы эшләренең иң җаваплы һәм авыр хезмәт булуы – билгеле хәл. Ә малчылыкта – бигрәк тә. Бар эшләр дә кул көче белән эшләнгәндәге авырлыкларны хәзер инде сөйләп, аңлатып та бетереп булмый. Кул белән 15 - 20шәр сыер сауган кешеләрнең кул-аяклары, билләре сызлауга әйләнгән чакта сөтнең торбалардан үзе ага башлавы, башка җиңеллекләр тугач, аларның куанычы, рәхмәтләре чиксез иде.

Наил Шәрәфетдиновның да мондый эшләргә керткән өлеше зур булды, – диде Гомәр абый Гайсин.

Элгәре авылдагы тормыш кайнап торган, яңа өйләр арткан, һәр йортта кимендә 4 - 5 бала үскән һәм халык ашкынып, бер-берсен уздырырга тырышып яшәгән, бәрәкәтле вакытта үскән кешеләр – бәхетле халык.

Тулы канлы авыл тормышында эштә чыныгып үскән буын кешеләре, үткәндәге якты истәлекләрен саклап, тормышның ямен тоеп, кадерен белеп яшиләр.

Наил абый һәм Гүзәл апа Шәрәфетдиновларның балаларында, оныкларында бу тормышчанлык, үҗәтлек аеруча ачык күренә.

Әти-әниләре хакында һәм үзләре үскән вакыттагы хәлләр турында алар сагынып һәм хозурланып сөйлиләр. Мәсәлән, аларның кызлары Наилә түбәндәгеләр белән уртаклашты.

– Без тату, ягымлы йөзле, эшчән һәм булган кешеләр гаиләсендә тәрбияләнеп үстек. Тәрбияне көчләп тагып булмый. Гаилә атмосферасы, кешене һәрьяклап чорнап, үзеннән-үзе аның һәр күзәнәгенә үтеп керә.

Аллаһыга шөкер, без тик уңай хисләр дулкынында тәрбияләнеп һәм эштә чыныгып үстек. Ике малай артыннан соң көтеп алынган кыз булгангадыр, мин әниемнең күңел җылысын һәм мәхәббәтен аеруча нык тоеп үстем. Шуңа да аңа карата хөрмәтем һәрвакытта көчле булды һәм аны югалтуны авыр кичердем.

Әтиемә килгәндә, ул – һөнәр ияләре нәселеннән. Аның әтисе Садршәһит бабай авылдагы беренче механизаторлар исәбендә булганга, әтием дә үз гомеренә механизатор һәм тимер эшләре, механизмнар көйләү остасы булып яшәде. Ә аның карчыгы Шакирә әбинең туганы татар дөньясында киң танылган гармун ясау остасы – Гали бабай Гәрәев. Әтием әле аның белән гармуннар да ясый торган иде.

Аның тагын бер шөгыле – ул


Илдар, Алия Ганниевлар

иске мотоцикллардан халыкка әрҗәле мотороллерлар ясый иде. Авылга әле газ кермәгән вакытта бензин пычкысы алып, кешеләргә утын кисәргә ярдәм итте. Ә соңрак шуларны ремонтларга яисә чылбырларын үткенләп бирергә ярдәм итә торган иде. Халыкның башка гозерләрен дә үтәгәнгә, аның яныннан бер дә халык өзелмәде.

Әтиемнең тагын бер һөнәре – ул унҗиде ел буена тегермәнче булып эшләде. Ут чыгып янган тегермәнне аякка бастырып, халыкка хезмәт күрсәтте. Он тарттырырга тирә-як авыллардан да киләләр иде. Халык телендә ул тарттырган оннан пешерелгән ипигә сокланып: “Наил күмәчләре”, – дип сөйлиләр иде.

Атнасына бер мәртәбә тегермәнне без бергәләп тулысынча җыештырып чыга идек. Абыйларым армиягә киткәч, мин аның төп ярдәмчесе булдым. Малларны да күп тотканга, әле печән дә чаба идем. Яшьтән эшкә өйрәнеп үскәнгә, мин аларны авырсынып түгел, теләп, ашкынып башкара идем.

Укуга килгәндә, әтием әле минем өй эшләрен тикшерергә дә вакыт таба иде. Шуңа да тырышып, яхшы укыдым. Башта техникум тәмамладым. Эшләгән вакытта, авыр булса да, читтән торып югары белем дә алдым. Әлбәттә, гаилә, балалар да булгач, авырлыкларны күп җиңәргә туры килде. Тырышлыгымны бәяләп, миңа зур компаниядә баш бухгалтер вазыйфасын йөкләделәр. Эшемне яратам һәм аннан канәгатьмен. Ике кыз үстердек, икесе дә югары белем алдылар, магистратура бетерделәр.

Әниемне алганда, ул аш-суга оста иде. Балачактан мине дә моңа өйрәтте. Төрле ризыклар пешерүне мин авырсынып түгел, чын күңел биреп, яратып башкарам. Ирем дә моны бәяләп, кызларыма: “Әниегездән менә шулай тәмле итеп пешерергә өйрәнегез!” – дип мактап куя.

Авылда үткән балачакны, мәктәп елларын мин сагынып искә алам. Пионер, комсомол оешмаларында актив катнаштым һәм әле аларны җитәкләдем дә. Шулай ук спорт белән дә шөгыльләндем һәм яхшы укыдым да. Әлбәттә, болар әти-әнидән бирелгән, миңа бай мөмкинлекләр тудырганга аларга бик рәхмәтлемен.

Әтиебез инде олы яшьтә. Без даими рәвештә аның янына, авылга кайтып, хәлен белешеп торабыз, – диде Наилә.

Әби-бабасы янында, аларның мәхәббәтен тоеп үскән кешеләр аеруча бәхетлеләр. Наил һәм Гүзәл Шәрәфетдиновларның оныгы **Алия Шәрәфетдинова-Ганниева** – менә шундыйлардан. Ул түбәндәгеләрне сөйләде.

– Әби-бабам, әти-әнием тормышчан, уңган кешеләр булганга, мин алар үрнәгендә һәм һәрнәрсәне үзләре белән киңәшеп эшләдем. Яшьтән хезмәттә чыныгып үскәнгә, авылда маллар тотып, тулы җанлы хуҗалык алып барабыз. Ирем Илдар да авылда уңган кешеләр булып танылган Ганниевлар нәселеннән.

Бабам турында һәрвакытта кешеләрдән рәхмәт сүзләрен ишетеп, аларга карата булган халык хөрмәтен тоеп үстем. Алар гел киң күңелле, ярдәмчел булганга, тормышта мин дә алар үрнәгендә яшәргә тырышам, – диде Алия.

Ачык йөзле, киң күңелле, мәрхәмәтле һәм ярдәмчел кешеләр тормышка ямь бирәләр, аңа бәрәкәт өстиләр. Алар янында яшәү дә күңеллерәк, мәгънәлерәк. Бу хакта уйлаганда гел Ринат Харисның “Кеше кайчан матур?” исемле шигыре искә төшә:

*Кеше кайчан матур була?*
*Кеше матур шул чакта -*
*башкаларны чакырганда*
*үзе яккан учакка;*

*ятлар белән танышканда*
*күзләре җылынганда;*
*шул җылылыкның рәхәтен*
*җаның белән тойганда.*

*Кеше кайчан матур була?*
*Кеше матур шул чакта -*
*ерак дусын очраткачтын,*
*елаганда кочаклап;*

*җырлаган чакта җырының*
*моңында эрегәндә;*
*бәхеткә таба чапканда,*
*куршеңә юл биргәндә.*

*Кеше кайчан матур була?*
*Кеше матур шул мәлдә -*
*шигырь тыңлаган чагында*
*уйга чума белгәндә;*

*мәхәббәтен сүзсез генә*
*аңлаткан мизгелендә;*
*бәхет белән сөйләшкәндә*
*бәхетнең үз телендә.*

*Кеше кайчан матур була?*
*Кеше матур шул мәлдә -*
*иң авыр минутында да*
*тормышка гашыйк хәлдә;*

*сөйгән ярын югалтса да,*
*сөюен саклаганда;*
*иң «гөнаһлы» гыйшыкның да*
*сафлыгын аклаганда.*

*Кеше кайчан матур була?*
*Кеше матур шул вакыт -*
*иле өчен, халкы өчен*
*яшәгәндә җан атып;*

*замананың авырлыгын*
*җилкәсенә алганда;*
*олы данга ирешеп тә,*
*кече булып калганда.*



***Где бы ни встречались представители тюркских народов: среди гор Кавказа, в Сибири, в Центре России или в степях Средней Азии, они везде легко могут понять друг друга. Это из-за того, что они происходят из одних корней. Одним из общих предков для многих народов являются кипчаки.***

***Фарид Ширияздaнов***

# История кипчаков глубока, романтична и загадочна

Как отдельный этнос, кипчаки сейчас уже не существуют, так как они растворились в среде других тюркских народов, составив основу их языка, культуры и традиций, идущих с глубокой древности.

Так какими же были наши предки?!

***В X–XII веках существовала огромная страна, называемая Дешт и Кипчак. Это было конфедеративное государственное устройство в виде союза племен и родов с тюркскими корнями. В те времена именно они были основными носителями тюркского духа, обычаев и традиций.***

Страна кипчаков имела огромные размеры и раскинулась от Байкала до Черного моря (тут нельзя путать понятия «страна» и «государство». Страна – ореол обитания народа, а государство – инструмент управления страной).

Кипчаки оставили глубокий след в истории не только татар и башкир – своих прямых потомков, но и других народов, обитающих на широких просторах Евразии.

Прошлое русского народа также неразрывно связано с историей кипчаков (которых они называли половцами). Во время многих сражений они призывали на помощь своих соседей – кипчаков, за их удаль и бесстрашие в бою.



За красоту и ум кипчакских женщин русские князья считали за честь жениться на них. Об этом можно привести много примеров. Например, взять хотя бы Александра Невского – мать и бабушка его были половчанками. Мать Ярослава Мудрого, Андрея Боголюбского и многих других князей также были половчанками.

Это и понятно: у народов, живущих по соседству, возможны межнациональные браки.

Особенно сильное влияние кипчаки оказали народам, проживающим в горах Кавказа. Надо признать и то, что черты характера, традиционная одежда, зажигательные танцы, музыка этого древнего народа наиболее ярко сохранилась там.

Поразительным фактом является то, что кипчаки принимали активное участие в решении судьбы грузинского народа (да и армянского, азербайджанского и других народов Кавказа тоже). Именно кипчаки дали возможность этим народам обрести свободу и в дальнейшем сохранить свой суверенитет.

***Грузины хранят особенно большую благодарность в отношении кипчаков. Было время, когда их страна была окончательно обескровлена в результате бесконечных боев за свою свободу и независимость с Персией, с Римской империей и другими захватчиками.***

Шестнадцатилетний царь Грузии Давид Строитель вынужден был искать союз с кипчаками. После завоевания значительной части Грузии захватчиками он обратился к кипчакскому хану Шарухану с просьбой о помощи. Тот отправил своего сына Артыка со своим сорокатысячным войском (если считать и членов их семей, то их число достигало до 200 тысяч).

Это был героический прорыв кипчаков, живущих в предкавказских степях: сквозь горные перевалы, пробивая себе дорогу, они сражались с разными горскими народами, которые защищали свои пастбища.

По приезде в Грузию царь Давид разместил кипчаков на лучших землях. Чтобы окончательно закрепить союз с кипчаками, он женился на дочери хана Артыка, которую звали Турандот.

Очарованный ее умом, красотой и грацией персидский поэт Низами тогда писал: «Рядом с Турандот и кипарис кажется кривой!»

Имея ввиду ее многогранные достоинства он писал, что женщины должны быть именно как она, то есть жидкой и живой как вода, чтобы:

- умела принять любую форму,
- не сгореть от страсти,
- просочиться в самый мелкий капилляр,
- утечь бесшумно в нужный момент,
- растворить все неприятности,
- не быть раздавленной,
- быть всегда необходимой,
- уметь добиваться своего, по капле капая на мозги,
- быть подобной водопаду в любви,
- быть нужной, как летний ливень в жару,
- быть радостной, как фонтан
- и неотвратимой, как цунами.

Турандот – означает «Дочь Турана», то есть является дочерью степей и носителем всего ценного и прекрасного, чем владел ее народ – кипчаки.

В Грузии её любовно называли на свой лад – Гурандот. Слава о ней разлетелась не только по этой стране, но и далеко за ее пределами. Про нее складывали стихи, песни, легенды и сказки. По одной из сказок написали оперу, которую исполняют на протяжении многих веков.

Кипчаки оставили глубокий след во всей истории Кавказа. Многие из них расселились по всему Кавказу. Например, в Армении раньше был даже город с компактным проживанием кипчаков. К сожалению, сейчас там об этом говорить не принято. Правда, в Азербайджане к их истории относятся с большим уважением. Тут уместно вспомнить кумыков, балкарцев, черкесов, адыгейцев и других.

Но самый неизгладимый след кипчаки оставили в Грузии. Главная их заслуга состоит в том, что они помогли грузинам изгнать из страны захватчиков. В битве на Дидгорской горе грузины с кипчаками одержали сокрушительную победу над войском врагов, многократно превосходивших их по численности.

День победы, посвященный Дидгорской битве, является главным государственным праздником в Грузии.

Секрет столь поразительной победы над врагами заключается в хитрости, находчивости и несравненной отваге кипчаков. А ситуа-




**Рис. 30. Схема расположения в степях кимаков, кипчаков, половцев, куманов.**
I — Венгрия; II — Болгария; III — Грузия; IV — Волжская Болгария.
1, 2 — северная граница степей; 3 — кочевнические общности;
4 — основные направления кочевнической экспансии в конце X–XIII вв.
По С. А. Плетневой



ция была такова: перед грандиозной битвой около сотни кипчаков под видом сдачи в плен пошли к вражеским войскам, под плащами спрятав свои мечи. Находясь в гуще врагов, они неожиданно вынули мечи и начали крушить их и в первую очередь обезглавили военачальников. От неожиданной их дерзости в стане врага произошло смятение. Пользуясь этим, кипчаки и грузинские войска кинулись в атаку и в конечном итоге одержали крупную победу.

